Әлфия Ситдикова

Утлы җимеш

Шигырьләр

Казан

Татарстан китап нәшрияты

2011

УДК 821.512.145-1

ББК 84(2Рос=Тат)-5

С48

**Ситдыйкова, Ә.М.**

Утлы җимеш : шигырьләр / Әлфия Ситдыйкова ; кереш сүз авт. Р.Гаташ. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2011. – 143 б.

ISBN 978-5-298-01853-1

Әлеге китапка Әлфия Ситдыйкованың туган җиргә мәхәббәт, ил язмышы, яшәү мәгънәсе турында уйланулардан торган шигырьләре туплап бирелә.

УДК 821.512.145-1

ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-01853-1

© Татарстан китап нәшрияты, 2011

© Ситдыйкова Ә.М., 2011

## Шигырь күзләрендә – Сөю һәм Наз

Шигырь язучы хатын-кызлар күп, ә шагыйрәләр аз, диләр.

Шагыйрә Әлфия Ситдыйкованы исә мин тиз кабул иттем: бөтенләе белән җаныма якын иттем дип тә әйтә алам. Нигәме? Үзем дә аңлата алмаслык бер ышаныч, ягымлылык, наз тулы дөньяга теләктәшлек, иш күреп үз итү, шагыйрәнең ихлас хисләренә, туган җиргә, кешеләргә һич бетмәс-үтмәс мәхәббәте белән күңелдә кабат үзем дә яңару кебек кичереш-халәт белән очраштым мин. «Җанда кабынган учак» та, «Йөрәгемә яфрак сыена» (китап исемнәре дә нинди ягымлы, җанга ятышлы бит) исемлесе дә минем әйбәт шигырьдән һич тә туймаган, гел сусаган җаныма бер тансык сусын-сут булып ятты дия алам.

«Бер җылы сүз» һәм «Өр-яңа котлаулар» кебек специфик характердагы киң катлам укучыларга аталган китаплары да шагыйрәнең күңелдә туган матур сурәтен һич тә үзгәртмәде; юк, киресенчә, тормышчан бер нечкә аһәң-наз, нәкъ менә хатын-кызга гына хас бер яктылык, кайгыртучан җылылык, ярату белән өретелгән ак күңел, дога-фатихалар тулы милли җан иясен тулыландырып күрсәтте бугай.

«Утлы җимеш» дип аталган әлеге җыентыгында да Әлфия ханымның мөлаем портреты шулай җанлана: кешеләргә ак теләкләр белән җылы сүз иясе – шагыйрә биредә дә үзенә тугры: һәр шигыре сөю белән тулы, алар наз, вәгъдә, бәхет көтүдән аз гына сагыш белән каймаланган, әмма анда – мәхәббәт, сүрелмәс, кимемәс ялкын, мәңгелек Сөю уты...

Әлфия – Актаныш районы Күҗәкә авылы кызы. Пучы мәктәбен тәмамлаган. Аннан соңгы тормышы Яр Чаллы белән бәйләнгән. Һәм «Күңел» радиосы белән! Табигый дә: шагыйрәнең күңеле язганнарында шәрран яра бит, һәм шунда аның хисләр, хыяллар биографиясе... Һәм, шулай дип әйтергә яраса, язмышлар яры, «мәхәббәт географиясе» дә! Барысы да үзен үстергән матур табигатьле, бик күп талантлы кешеләр бишеге – Актаныш белән бәйләнгән. Аның авыллары, елга-чишмәләре, урман-кырлары белән... Шул як кояшы, ае белән туган аның шигырьләре, аларда – гөлләрнең хуш исе, әрем тәме катнаш моң һәм бабайлар васыять иткән туган туфракка тугрылык, нигезне изге санау кебек әдәп-әхлак иманы, Мәңгелек Моң... Менә нинди ул Актаныш ягында канатланган шигъри күңел тәрбиясе! Һәм мин, бу якларның күптәнге гашыйгы, һәр яңа талантка хәер хаһ булган якташ шагыйрь – яңадан бу дөнья белән очрашып әсәрләндем, гүяки хисләремдә яшәрдем. Ихласлыкның әнә шундый көче бар, туган телнең шулай тетрәндерә торган сихри тибрәнешләре, моң-аһәңнәре бар. Көен генә боза күрмәсеннәр, тупас куллар белән генә кагылмасыннар. Яшермим, Әлфиябез тормышка якын көндәлек күренешләрен шигырь итәсе килеп, проза белән очрашкан моментлары да очрый, кабатланулар да... Бөтен авыл атамаларын да җыр итү теләге дә сизелеп куя... Әмма тулаем күңел эзләнүләрендә ул әнә шул ихлас җыр-моң белән еш кавыша, үзе дә сизмәстән, канатлана, оча, яңача яңгырый ала. Димәк, шагыйрәдә җырга якынлык табигый рәвеш тә бар, ул көй сорап яши, дәвам итә. Шул юлга тугры булуын теләргә генә кала.

Тумыштан ярату, мәхәббәтне олылау сәләтенә ия Әлфия бу изге хискә ышанычын мәңге югалтмас дип уйлыйм.

Яз, шагыйрә, ян, үзең булып кал!

*Рәдиф Гаташ,*
*шагыйрь, Татарстан Республикасының*
*Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты*

* * *

Мин дә каен, минем дә бит
Тамырларым тирәндә.
Җәен мин дә яланаяк
Басам яшел чирәмгә.

Көзгә керсәм, каен сыман
Сагышланам, моңланам.
Яфрак-яфрак көннәремне
Җилләр өзә еллардан.

Кышка керсәм, мине дә бит
Суыклар өтеп ала.
Кыш тамгасы каен тузда,
Минем чәчемдә кала.

Язын каен ак күлмәген
Яңадан юып кия.
Минем дә күңел каендай,
Аклык, сафлыкны сөя.

Мин дә каен, минем дә бит
Тирәндә тамырларым.
Яшел – яшәү төсе диеп,
Яшел шәл ябынамын.

## Ак чишмәле илем

Туган җирем – чып-чын татар иле,
Исеменә аклык кушылган.
Актаныштай иркен күңелемә
Ак чишмәләр койган шушыннан.

Ана теле минем сөйләм телем,
«Әннә» диеп телем ачылган.
Авыл тәрбиясе җанда яши
Ялантәпи йөргән чагымнан.

Чирәмнәргә төшкән чыктан күчкән
Сафлык яши минем җанымда.
Бүләк итеп бирдем балаларга
Шул сафлыкны кушып каныма.

Туган җирдән аерылган мәлдән
Күңелемдә яши ак сагыш.
Ак күңелле якташларны сагынып
Кайтам сиңа, кайтам, Актаныш.

* * *

Очам күккә синең кочагыңда,
Йолдыз тузаннары кала дулап.
Җилдәй җитез гомер узып бара,
Болан баласыдай йөгереп уйнап,
Җәйләремнең үзәннәре буйлап.

* * *

Минем дөньям чиксез галәм төсле:
Яши ятлар, яши якыннар.
Үз дөньямны шаулы бакча итеп
Яшәр өчен тулы хакым бар.

Якыннарга үзем ишек ачам,
Ятлар әрсез, керә сораусыз.
Өннәрем бар күгем яктыртучы,
Төшләрем бар калган юраусыз.

Назларым бар, якты язларым бар,
Шаулап чәчәк аткан аланым.
Чиксез бәхет, ишетәм һәр мизгел
Шат тавышын газиз баламның.

Сөюем бар җанны җылытырга,
Җырларым бар халык өчен дә.
Сыенам мин асыл хакыйкатькә,
Бар бәхетем яшәү көчендә.

* * *

Туганда ук маңгай күзен биргән,
Яши-яши күңел күзләрен.
Шушы күзләр белән мин дөньяның
Танып, аңлап яшим серләрен.

Замананың ачы җилләреннән
Каралмасын өчен йөзләрем,
Гомер сукмагында адашмаска
Юлдаш иттем вөҗдан күзләрен.

* * *

Үз-үземне табар өчен күпме
Сүткәнмен мин гомер йомгагын.
Үкенмәслек итеп яшәдемме
Артта калган яшьлек елларын?

Инде таптым үз-үземне дигәч,
Язмыш куя алга зур сынау.
Мөмкинме соң узган мизгелләрне
Хәтерләрдә барлап юксынмау.

Мин үземне танытырга түгел,
Таныр өчен яшим дөньяда.
Мин – бер инеш, сафлык өстәргә дип
Кушылучы олы елгага.

* * *

Ил ялгышын, ир язмышын уйлап
Яши шагыйрь һәрбер мизгелдә.
Иле өчен, халкы өчен яшәп,
Тауга менә, төшә диңгезгә.

Пычак белән телгәләнгән кебек
Тоташ яра шагыйрь йөрәге.

Җанын ярып чыккан сүзләренең
Кешеләргә бармы кирәге?!

Яна-яна яши халкы өчен,
Сирәк була ләкин күрүче.
Ешрак шул мактау урынына
Көчек булып арттан өрүче.

*** * ***

Чәчемә көмеш кунса да,
Мин һаман әле бала.
Кайтам әнкәем янына,
Җаныма эзләп дәва.

Мактап бер сүз әйтә калса,
Күңелем канат кага.
Югала шулчак җаныма
Язмышым салган яра.

Кайчан кайтсак та, әниләр
Юатыр сүзләр таба.
...Җанына дәва эзләве –
Кызым күземә бага...

## Күңел

Күңел сандыгымны ачтым сезгә,
Йөрәгемдә ничә яра бар?
Сез хөкемдар бүген иҗатыма,
Бер җылы сүз, бәлки, дәвалар.

Үткәннәрем бар да сезнең алда.
Мин гөнаһлы гади бер кеше.
Үз-үземә язган шикаятьтә
Кайсыгызның күпме өлеше?

Үкенмим лә, бу бит минем язмыш,
Үпкәм дә юк минем үткәнгә.
Кем ялгышмый, кем хатадан хали,
Сикәлтәле юллар үткәндә?

Мин ничек бар, шулай яратыгыз,
Һәр кешенең җирдә үз юлы.
Күңел – арфа. Киерелеп-чыңлап
Өзелергә әзер һәр кылы.

## Мин яшим

Мин үлмәдем, исән, яшим әле,
Ашыкмагыз мине күмәргә.
Әйтеп бетермәдем әйтер сүзне,
Меналмадым биек үрләргә.

Күз җитмичә яфракларын коймый
Яр буенда үскән тирәк тә.

Туктатмагыз барыр сукмагымда,
Утлы хәнҗәр кадап йөрәккә.

Озын юлда һәрбер юлчы туктап
Бер тын ала арып-талганда.
Ышанмагыз, үлгән икән диеп,
Җилләр алып килгән ялганга.

Усал куллар балта белән чапса,
Агач ава, гүя тамырсыз.
Мин үлмәдем, исән, яшим әле,
Җырым аша мине танырсыз.

* * *

Туган авылым, һәр ел саен сиңа
Читтә йөреп арып
Зарыкканнар кайтып башын ия.
Кем булсаң да җирдә,
Туган туфрак
Башны идертерлек көчкә ия.

* * *

Кайткан саен, туган авылкаем,
Каршылыйсың җәеп кочагың.
Саклыйсың син хәтер төпкелендә
Бөтерчектәй җитез, ут чагым.

Назлап сыйпый туган якның җиле
Көмеш бәсле йомшак чәчемне.
Сиңа кайткач, күңел канатлана,
Онытам мин хәтта яшемне.

Кайткан саен гүя кабат туам
Һәм яшәрәм язгы гөл сыман.
Хушлашам да, капкаларны ябып
Чыгуга ук сине юксынам.

## Күҗәкә

Хуҗа әкә нигез салган
Биш йөз ел элек килеп.
Авылыбызга гашыйк бугай,
Кояш та чыга көлеп.

Туган авылым Күҗәкәнең
Йортлары ак нараттан.
Йөрәк юллары тоташа
Аңа бөтен тарафтан.

Иркен кырлар, әрәмәләр
Бар да Ходай бүләге.
Мәчет тавы, Ниргез ягы,

Чәтертәне, Бүләге.

Бишек җыры көйли таллар,
Сандугачлы тирәге.
Чишмә тибә таш астыннан,
Ул – авылым йөрәге.

* * *

Җитәкләшеп уздык бүген
Балачак урамыннан.
Күңел чапты бездән алда,
Бушанып тышавыннан,
«Бәрәңге урамы»ннан.

Яланнарда яшел үлән
Күмелгән энҗе чыкка.
Гармун тавышын эзләдек,
Төшкәндә түбән очка,
Чыланып көмеш чыкка.

Гармун моңы да яшьлектәй
Калган икән еракта.
Кайтарып булмый ул чакны,
Урамнарны урап та,
Тик кайтаваз колакта.

* * *

Җәй куенында миләш кызы
Утыра төймә тезеп.
Уттай кызыл җиләкләрне
Кабасы килә өзеп.

Кызыктырып, ымсындырып
Торса да тәлгәшләре,
Әчесе җанга тия шул,
Әйтерсең күз яшьләре.

* * *

Күмәкләшеп нигез салган йортның
Һәр бизәге безгә яхшы таныш.
Балачаклар шаулап шунда үткән,
Почмакларга качып калган сагыш.

Кайтуларны безнең көтә әнкәй,
Кочак җәеп һәрчак каршы ала.
Күңелләрдә шатлык күбәләге
Куанычтан канатларын кага.

Шаян күзле балачагым гүя
Мөлдерәпләр карый күзләремә.
Бу дөньяның бөтен назы сыйган
Әнкәемнең кайнар йөрәгенә.

## Илерү

Вөҗдансызлар басып алган,
Юлларда кара тузан.
Ярдәм сорап ил-халкыма,
Күкләргә кулым сузам.

Таш аталар өстебезгә,
Аш суза күндәм халкым.
Тыштан балкып елмайса да,
Эчендә дөрли ялкын.

Балга манып әфьюнны да
Йотканмы әллә халык?!
Тын алырга курка мәллә,
Кидергәч өстән калып.

Җанын сорап, Газраил дә
Явыз кулларын суза.
Үлем белән тарткалашкан
Ил өчен бәгырь сыза.

Сыктавымның кайтавазын
Ишетәсеңме, халкым?
Бар бит тезләнми дөньяда
Яшәргә синең хакың.

Ишетәсеңме, халкым?..

* * *

Халкымның йөрәге гел тоташ кан-яра,
Әйтерсең козгыннар җыелып чукыган.
Җуелган кыйбланы эзләүче булырмы,
Кайчан соң илкәем уяныр йокыдан?

Яз туа. Кабаттан яшәрә өметләр,
Юыла ләйсәндә язмышлар ачысы.
Ышаныч уяна күңелдә яз белән,
Ачылыр бер мизгел күкләрнең капусы.

Язларда яшәргән өметләр күзләрдә
Мул бирер уңышны – көтелгән бәхетне.
Акланыр, ышанам, ирекkә сусаган
Халкымның гасырлар өзмәгән өмете.

* * *

Барыбыз да язмыш колы,
Рәхмәтендә һәммәбез дә.
Тели – бирә өеп бәхет,
Тели – сагыш сала йөзгә.

Тели – кояш элеп куя
Яктыртырга күңел күген.
Сынар өчен иңгә өя

Таштай авыр тормыш йөген.

Утта, суда чыныктыра,
Тели – суга китереп тезгә.
Дөньялыкка килгән көннән
Язмыш колы һәммәбез дә.
*** * ***

Төймәдән дөя ясыйлар
Ашаучылар башыңны.
Син кабасың, алар йота
Алда торган ашыңны.

Тегермәнгә су коючы
Судан да коры чыга.
...И йөрәгем, ярылмыйча
Түз инде, чыда, чыда.

*** * ***

Кызыктырып яна, дөрли учак,
Битарафлык җанга хас түгел.
Иеләм дә утлы күмер алам,
Алданасың нигә, әй, күңел?!

Тагын сызлый уч төбендә яра,
Пешмәс дигән идем, пешергән.
Янмый гына чыгып буламы соң
Дөрләп янган учак эченнән?

Яши-яши төшендерде язмыш,
Янып яшәү – минем язмышым.
Утлы кузны җыям учларыма,
Тыңлый-тыңлый дөнья тавышын.

## Чыныгу

Үр менгәндә каршылыклар булса,
Үпкәләмим бер дә язмышка.
Күрәселәр күктә билгеләнгән,
Табышлар да, хәтта ялгыш та.

Көрәшләрдә җанны чыныктырып
Яшәр өчен җиргә килгәнмен.
Шөкер кылып кабул итәм шуңа
Тәкъдир язган һәрбер бүләген.

Сөенәм мин һәрбер аткан таңга,
Һәрбер көнгә, һәрбер мизгелгә.
Мин яшәгән һәр көн ул минеке,
Һәр минутын яшим үземчә.

Киртәләрне ватып үтәр өчен,
Рухи көч тә өстәп бирелгән.
Сукмагыма яуган яфракларга
Алтын йолдыз диеп үреләм.

Рәхмәт, язмыш, каршылыклар белән

Сыныйсың син минем ныклыкны.
Җиңелү һәм җиңү барын аңлап
Чыныктырып яшим холыкны.

* * *

Кашкарыйлар сулып ята
Ак кыраулар куенында.
Кем җиңелә, кемнәр җиңә
Яшәү, көрәш уенында.

Кемдер чишмә булып ага,
Тау-ташлардан басылса да.
Кемдер ава башын тотып,
Әз генә җил кагылса да.

Битарафлык тамыр җәя
Яшәү, көрәш уенында.
Кашкарыйлар сулып ята
Ак кыраулар куенында.

* * *

Гомер – йомгак. Сүтә-сүтә җебен
Кем үр менә, кемдер туктала.
Кем иелеп чишмә суын эчә,
Кем кояшка үрелеп ут ала.

Аз булса да хәсрәт килсә, кемдер
Яшен түгә иелеп тал сыман.
Ә кемнеңдер дымлы күзләренә
Сандугачлы алсу таң сыйган.

Әйләнә җир. Дөнья куласа шул,
Куып җитеп булмый дөньяны.
Сүтелсә дә йомгак, чуалмасын
Гомеремнең җырлы еллары.

* * *

Күпме яраланган күңел
Төзәлде җылы сүздән.
Кемнәр соң мине юатыр
Аралап сары көздән?!

Минем дә күңел пыяла,
Чәчелде ватыклары.
Кайтарырга мөмкин түгел
Югалган вакытларны.

Ваклап-ваклап өләшәмен
Кешеләргә җанымны.
...Кискән саен кими бара
Катгый тормыш кануны.

* * *

Минем дә бар җирдә үз урыным,
Үзем яулап алган үрем дә.
Кеше өчен кеше яши алмый,
Кеше керми кеше гүренә.

Һәркемнең дә горурлыгы була,
Җанны бәйләп торган йөрәге.
Арган чакта ятып хәл алырга
Күләгәсе булган тирәге.

Вакламагыз, кимсетмәгез шигырь
Язучыны, санап юләргә.
Мин туганмын тик үземчә яшьнәп,
Тик үземчә яшәп үләргә.

* * *

Җир түгәрәк, дөнья иксез-чиксез.
Мин бер юлчы шушы дөньяда.
Яраклашып яши белмим көнгә,
Борылалмыйм уңга, сулга да.

Туры атлыйм. Барган сукмагыма
Ишелеп төшә кайчак кыялар.
Әверелеп көлгә, артта кала
Канатлары сынган хыяллар.

Яшен яшьни, коеп яңгыр ява,
Барыр сукмак охшаш сазлыкка.
Тиле күңел өмет өзми һаман,
Әй ашкына аклык, сафлыкка.

Абынам да егылам, кабат торам,
Мин үтәргә тиеш юлым бар.
Халык күңеле төпсез дәрья сыман,
Тулган анда күпме моң һәм зар.

Моңлыларның башларыннан сыйпыйм,
Зарлыларны кочып юатам.
Дөнья тар ул, әгәр бар белгәнең
Булса синең корган ихатаң.

Юлым озын, иксез-чиксез дөнья
Бар бит әле иңләп үтәсем.
Белеп яшим, сукмак өзелгәндә
Офыгымда кояш сүнәсен.

Юк, куркытмый. Йолдыз атылганда
Ертып үтә төннең карасын.
Җаннан чыккан шигырь уты ялгар
Яшәү белән үлем арасын.

## Уй

Кайтаваздай ишетелә
Күк күкрәве еракта.
Ай ялтырап карап тора,
Охшап үткен уракка.

Уйлап куйдым шул мизгелдә:
Юкка түгел яшәвем.
Күкне телгән яшен булып
Мин дә бер көн яшьнәрмен.

*** * ***

Бар дөньяга хуҗа сыман йөри,
Кесәсендә акча булганга.
Бер елмаю бүләк итә алмый
Очраганда җаны туңганга.

Акча белән үлчи бар адымын,
Уйлый: җирдә бар да сатыла.
Дөнья гамен бар дип белмәгәннәр
Үкенә, баскач әҗәл катына.

## Әле ярый

Язылмыйча калды күпме җырым,
Ап-ак кәгазь бите – көннәрем;
Бер йолдызсыз калган, айсыз калган
Ялгызлыкта үткән төннәрем.

Сөюләрсез тормыш – буш мәгарә,
Тешсез авыз кебек караңгы.
Әле ярый яңа сөю кошы
Дәвалады йөрәк ярамны.

Әле ярый күңелдәге өмет
Ятим итеп ташлап китмәде.
Яңа җырны дәвам итәр өчен
Ачыла гомер-дәфтәр битләре.

*** * ***

Сискәндереп син бер әйткән идең:
«Әнкәемнең соңгы көзедер».
Тел очыннан тамып төшкән ул сүз –
Җан әрнеткән йөрәк сүзедер.

Кемнәргә соң газиз түгел Ана,
Кем курыкмый соңгы көзеннән.
Калтыранып соңгы яфрак төсле,
Тетрәп куйдым шушы сүзеңнән.

Сискәндердең, үзең сиздең микән?
Җаным туңды шушы сүзләрдән.
Өнсез калдым күреп моң ташканын
Дәрья төсле төпсез күзләрдән.

*** * ***

Мәхәббәткә дан җырчысын

Күпләр тыңлап саташкандыр.
Кызлар әгәр шигырь язса,
Күчкән моңы Гаташтандыр.

Мин дә күрдем сине, Шагыйрь,
Газәлләрең керде җанга.
Синдә янган шигырь уты
Әйди мине яңа таңга.

«Бирешмә, – дип дәшәсең син, –
Әле бары гомер башы.
Биек үргә менәсең бар,
Уя-уя кыя ташны».

Сүзләреңдә хаклык күрәм,
Рәхмәт сиңа, и Гашыйк җан!
Бүләк иттең көтмәгәндә
Өмет тулы өр-яңа таң.

Мин бүген бай, мин Гаташлы,
Күңелемә керде Гаташ.
Эчкерсез һәм олы җанлы
Мәңге гашыйк җырчы якташ.

Рәхмәт сиңа, Рәдиф Гаташ!

*** * ***

Елмайса да кояш нуры,
Җылысы җитми җанга.
Язда тамасы тамчылар
Әйләнгән гүя карга.

Әллә соң бу киң дөньяда
Язларга урын тармы?!
Җырлап гөрләвек агар чак,
Буранлап ява кары...

*** * ***

Наз тулы яз килде дөньяга,
Биешә кояшта тамчылар.
Иркә җил куенында назланып,
Бөреләр күзләрен ачтылар.

Ямьләнде табигать, яшәрде,
Төренде ал нурга бар дөнья.
Сыерчык тавышы моң булып
Каеннар тузына сарыла.

Таныш та, түгел дә кебек яз,
Яшьлегем кайтканмы борылып?
Гөрләвек чыңына кушылып,
Күңелдән җыр ага ургылып.

Наз тулы яз килде дөньяга...

## Яшел шигырь

Яшел үзән кочагында
Яшел имән тамыр җәйгән.
Яшел шәлен тибрәтергә
Яшәү көче ала җирдән.

Яшел яфрак – яшәү төсе,
Яшеллектә яшәү көче.
Яшьлек ямен югалтмыйча
Яшьнәп яшик имән төсле.

## Яз җыры

Яз җыры тарала дөньяга,
Каеннар ап-актан киенгән.
Каршылый язларны табигать
Өр-яңа, саф, чиста киемнән.

Яшәрә болыннар һәм кырлар,
Иркәли җилләрнең сулышы.
Яңгырый һавада сөенеп
Җыр сузган кошларның тавышы.

Бөреләр кояшка үрелә,
Татлы яшь түгәләр каеннар.
Гөрләвек чыңлата күңелдә
Кар-судан кушылган ярсулар.

## Караш

Ак кәүсәле каеннарның
Бөдрәләрен сүтә җилләр.
Кар сулары җырлап ага,
Кибеп килә уйсу җирләр.

Күңелләрне алгысытып,
Язлар безне алга дәшә.
Уттай янып, сары чәчкә
Бар җиһанга нурын чәчә.

Яңа туган тал песие
Төренгән дә күк мамыкка,
Елтыр күзен мөлдерәтеп
Карап тора дөньялыкка.

## * * *

Күңел кылын өзгәләмә,
Туктап торчы, сандугач.
Ничек яшим, йөрәгемә
Мәңге бетмәс моң тулгач.

Ник сайрыйсың өзгәләнеп,
Телгәләп бәгыремне.

Болай да сары сагышлар
Кыскарта гомеремне.

## Ләззәт учагында

Фәрештәләр канат куйды иңгә,
Әйтерсең лә җаннар күккә ашты.
Йөрәкләргә тулган наз тамчысы
Эретер төсле хәтта кыя ташны.

Ак болытлар йөзеп үтте күктә,
Ялтырады мәчет манарасы.
Ишетелде азан тавышлары.
Күңелдә моң – Казан манзарасы.

Дөрли җаннар ләззәт учагында,
Күзләр – йолдыз, битләр – алсу алма.
Вакыт дәрьясында бу мизгелләр
Хатирәләр булып уелып кала.

*** * ***

Давыл тулы йөрәгемә
Килеп кергәч куркып калдың.
Сөю уты көйдергәндер
Нечкә хисле горур җаның.

Чыкмам, янар чәчәк тотып,
Синең барыр юлларыңа.
Давыл кошы булып кына
Калыйм синең уйларыңда.

*** * ***

Сагынасыңмы диеп сорыйсың син,
Тыным белән тартып алыр идем.
Вакытлыча түгел, мәңгелеккә
Яннарыңда синең калыр идем.

Күңел борчуларың барсын җыеп
Илтеп салыйм әле агымсуга.
Яшәү көче өстәп йөрәгеңә,
Җан учагым сиңа ялкын суза.

Гомер буе сине җылытыйм дип,
Әйләнәмен утлы бер ялкынга.
Сагынасыңмы диеп сорап торма,
Тының белән тартып ал яныңа.

*** * ***

Көпә-көндез, йокламаган килеш,
Төшләремдә бүген сине күрдем.
Күптән көткән, җаным өмет иткән
Кызыл гөлләр миңа өзеп бирдең.

Сөюеңнең билгесе дип сусап
Кулларыма алган гөлләрең
Шиңде кинәт минем кочагымда,
Булып синсез үткән көннәрем.

Көпә-көндез сине төштә күрдем...

## Яшен

Кушып булмый ике ярын бергә
Язмыш дигән тирән елганың.
Син бер якта, мин икенче якта
Сүтәбез шул гомер йомгагын.

Уйлар гына кушылып бергә ага,
Үзгәртергә теләп язмышны.
Соңлап килгән уртак сөю хисе
Ялгышмы соң, әллә табышмы?!

Төйнәп куйыйк әле күңелләргә
Түгелергә әзер күз яшен.
Җанда купкан давыл-гарасатны
Телеп үтсә үтсен ут-яшен.

## Тимә

Карама син күзләремә,
Тимә, тимә керфегемә.
Йөрәгеңә яра салыр,
Төшсә әгәр бөртеге дә.

Карашларың керпе генә,
Әйтерсең лә утлы энә.
Җылы сүзләр әйтеп калып,
Күңелемә берүк тимә.

Тимә, тимә йөрәгемә,
Тиеп ялгыш канатырсың.
Юатыйм дип назларсың да
Үзең сизми яратырсың.
Гомер буе җан атарсың.
Яратырсың...

## Керфек җиле

Җәй кызуы сүрелмәгән әле,
Эсселеге җанны көйдерә.
Йөрәк көчкә түзә, ярсуыннан
Әйләнмичә утлы күмергә.

Керфек кактың, сәмум җилен басып,
Сафлык килеп керде күңелгә.

Синең өчен ярты җанымны да
Бирер идем шушы мизгелдә.

Сихерме бу, әллә яратумы,
Әллә бары назга сусаумы?!
Керфек җиле өзде мине кысып
Җан әрнеткән утлы кыршауны.

* * *

Күңелемдә боз кузгалды,
Сыешмый ярларына.
Көтмәгәндә учак яктың
Барыр сукмакларыма.

Көтмәгәндә килеп чыктың
Томаннар арасыннан.
Бозлар эри, җаным эри
Наз тулы карашыңнан.

Кар сулары китә агып,
Ярсулар бетәр микән?!
Бу күрешү, әйтче миңа,
Гомерлеккәме, иркәм?!

* * *

Алларымда пар алмалар:
Берсе яшел, берсе ал.
Татып карыйм: берсе әче,
Берсе – телең йотар бал.

Көннәр дә бит шул алмадай:
Берсе тора шатлыктан.
Берсе йөзне саргайтырлык,
Картайтырлык сагыштан.

* * *

Киләм диеп хәбәр бирсә иркәм,
Кар өймә, җил, аның алдына.
Кышкы салкыннарда җылытучым,
Юатучым бары ул гына.

Тыны белән эретә ала бары
Тик ул гына туңган җанымны.
Бураннарны баса күз карашы
Һәм кайтара яшьлек таңымны.

Аның белән генә татыдым мин
Сөю, сөелүнең чын тәмен.
Юлга чыгып килеп җитми калса,
Күтаралмас кебек йөрәгем.

## Кар яуганда

Сизеп торам, ерак булсаң да син,
Күңелең бит миңа ашкына.

Ярсу йөрәгеңне басар өчен
Чыгасыңдыр җилләр каршына.

Шуңадыр ул салкын кышларның да
Җиле исә мине иркәләп.
Менә тагын, кочакларын җәеп,
Иңгә кунды ап-ак күбәләк.

## Җанда сөю ялкыны

Очар кошым, сайрар сандугачым,
Кыяларга кунган бөркетем.
Гомер күзләренә нур сирпергә
Кабыздың син соңгы өметем.

Яраттырдың һәм үзең дә мине
Ничек булсам шулай яраттың.
Юл күрсәтеп, учак якты алда
Назга тулы җылы карашың.

Соңгы яну, соңгы кабынуым,
Соңгы сөю, җанда ялкыны.
Соңгы җырның сүзен көйгә салып,
Тибрәтәсең моңлы сазымны.

## * * *

Кемгә килә сөю иртә язда,
Кемгә соңлап алтын көзләрдә.
Кемдер эчә татлы чишмә суын,
Сагыш яши күпме күзләрдә.

Сөелеп тә сөялмаган ярлар
Яши әле җирдә тилмереп.
Кемнәрнедер күккә чөйгән сөю,
Парын җуйгач, йөри илереп.

Яраттырган һәм яраткан өчен
Хөкем итеп карар чыгарма.
Көлеп яшим, керфекләрем генә
Таң чыгыдай яшькә чылана.

## Онытالсаң оныт

«Белмим синең үткәнеңне,
Белмим киләчәгеңне.
Белмим, синең белән булсам,
Ниләр күрәчәгемне.

Бәхетемме, тәхетемме,
Ләхетемме син минем?»
Өзгәләнеп, ниләр уйлап
Бүген син шулай дидең?..

Мин бит сиңа борчу булып түгел,
Якты сөю булып килгән идем.
Нигә бүген миңа «Син бәхетме,
Әллә инде ләхетемме» дидең?!

Ничек итеп җавап бирим сиңа, –
Йөрәгемне минем яраладың.
Вакыт үзе безгә сынау булсын,
Көтик әйдә томан таралганын.

Шик-шөбһәләр булса күңелеңдә,
Читкә китәм, тота күрмә мине.
Яшәртергә теләп бүләк иткән
Сөю уты өтсә йөрәгеңне,
Кичер мине. Әгәр булдыралсаң,
Оныталсаң, әйдә оныт инде.
Үлемнәрне җиңеп, тик шулай да
Чыңлар безнең шашып сөю хисе.

* * *

Мин киткәндә көзләр елап калыр,
Кара кайгы сарыр дөньяны.
Сүзсез генә галәм карап торыр
Җирнең яшен яңгыр юганны.

Мин киткәндә урман шавы башка,
Башка булыр шавы дулкынның.
Сары яфрак булып җиргә ятар
Бар моңнары соңгы җырымның.

Чын күңелдән елаучылар булыр,
Аңлап киткәч кабат кайтмасны.
Әкрен генә авылдашлар салыр
Җәсәдемә соңгы япманы.

Киткәнемә горур яшәп җирдә,
Шагыйрь дигән затлы ат алып,
Каршы алыр бакый дөньялыкта
Ата-бабам рухы, шатланып.

## Йолдыз нуры

Тәрәзәдән карап сине көттем,
Керфекләрем талды.
Таңга кадәр, миңа туры карап,
Якты йолдыз янды.

Күз яшьләрем җиргә әкрен генә
Тамчы булып тамды.
Сөю уты йолдыз нуры булып
Йөрәгемдә калды.

## Түзәрсеңме?

Тәү күргәндә уйламаган идем
Уралырмын диеп серләреңә.
Йөрәгеңне ачтың. Яра аша
Ялангач җан бакты күзләремә.

Игезәкләр кебек безнең җаннар...

Бәргәләнә язмыш кочагында.
Тоташ уттан торган йөрәгемне,
Түзәрсеңме, салсам учларыңа?!

* * *

Көчем җитми үзгәртергә
Язылган язмышларны.
Үзәгемне өзеп ала
Ялгыз каз тавышлары.

Каз каңгырып очканга да
Сызлана йөрәк ярам.
Күрәсең бит, туктатмыйсың,
Утларга кереп барам.

Үкенерсең, тик соң булыр,
Көл булып очсам җилгә.
Тотса сөю каргышлары,
Ничек яшәрсең җирдә?!

Беләсең бит, синең кулда
Киләчәк язмышларым.
Ут-ялкыннан аралап ал
Гомерем агышларын.

* * *

Йомшак куллар чәчтән сыйпый,
Күзләремдә синең күзең.
Пар алмадай алсуланды
Шатлык нуры сипкән йөзем.

Килдем, күрдем, инде китәм,
Ачуланма миңа, иркәм.
Син үзең үк үкенерсең,
Дөрли-дөрли янып бетсәм.

Ачуланма күңелемне
Алгысытып киттең диеп.
Җылы назлар күңелемдә
Тыпыр-тыпыр кайта биеп.

* * *

Кылдан нечкә, нәфис хисләр бәйли
Икебезнең йөрәк арасын.
Хыялларда бергә җитәкләшеп
Кичәбез без төннең карасын.

Якты өмет кул сузганга күрә,
Кабат балкып ата таңнарым.
Соңлап килгән сөю белән шулай
Раббы сыный гашыйк җаннарын.

* * *

Төн кочагы икебезгә уртак.
Кайнар тәннәр бии ут-ялкында.
Тәннәр генә түгел, җаннарыбыз
Кушылган күк бергә хис-ташкында.

Иреннәрең сөеп назлый мине,
Сусавымны басып чишмә ага.
Төн узса да, безнең күңелләрдә
Сүрелмәслек учак яныш кала.

Төн кочагы икебезгә уртак...

*** * ***

Соңгы кат назланып кочакта
Үксегән сабыйдай боегып,
Кара җир өстенә төшәлә
Алтындай яфраклар, коелып.

Соңгы кат каңгылдый кыр казы,
Иңрәвен яшереп йөрәккә.
Үксеми китүләр илеңнән
Авыр шул, авыр шул бигрәк тә.

Соңгы кат борылып карадың,
Ялвару яшереп күзеңә.
...Пышылдыйм: «Сак белән Сок бүген
Дөньяда без генә, без генә...»

## Парлы бию

*(Америка шагыйре Уолт Уитменга ияреп)*

Тынып йоклый урман, иркен кырлар,
Дулкыннарны сыендырган ярлар.
Алан уртасында учак дөрли,
Учак тирәсендә бии бер пар.

Йолдызларга кызык. Әле берсе,
Әле икенчесе парны күзли.
Ике гашыйк иреннәре белән
Сусыннарын басар чишмә эзли.

Аңны буйсындырган татлы хистән
Башын җуяр хәлдә асыл егет.
Кызган таш астыннан кайнар чишмә
Бәреп чыга булып яңа өмет.

Бармаклары белән ал чәчәкнең
Таҗларына егет кагыла да
Алиһәсен үбә. Сүнгән дәрте
Әзер тагын дөрләп кабынырга.

Бөтен җиһан балкый якты нурдан,
Җир дә, күк тә, су да, болын, урман.
Бәхет бишегендә тирбәлергә
Сабый төсле яңа ал таң туган.

* * *

Баһадирдай ирнең кочагында
Пар алмалар, нәфис калкулык...
Кыяр-кыймас күзләр күзгә бага,
Тәннәр тәнгә тия тартынып.

Кайнар сулыш өргән уймак авыз
Наз чишмәсе – телне яшергән.
Шушы мизгел кышкы суыкта да
Саклап торыр кебек өшүдән.

Бии наздан һәр күзәнәк тәндә,
Татлы аваз җанны иркәли.
Акылларны җуйдырырлык хистән
Туган сөю шушы микәнни?!

Аһ, бу назлар! Оныттыра барсын.
Дөнья мәшәкатен, борчуын.
Нинди ләззәт ялкын телләрендә
Канатланып бергә очуың.

Җиргә килеп еллар яшәвеңнең
Төп мәгънәсе шушы мизгелме?
Җаннар кушылуы ычкындыра
Куллардагы ныклы тезгенне.

Туганчы ук шушы утлы сөю
Дәшкән мәллә безне үзенә?
Бии наздан һәр күзәнәк тәндә,
Аң бирелә дулкын көченә.

Яңа сөю җыры туа таңда,
Җан кушылып җаннар ярала.
Тәннәр тәнгә берегеп утта яна,
Пар алмалар бии арада.

* * *

*Чечняда хәбәрсез югалган авылдашым*
*Рөстәм Мөхтәсәр улы Мияссаровның әнисе*
*Фәния апага багышлыйм.*

Грозныйда канлы сугыш бара,
Сындырырга теләп иманны.
Ике башлы каракошның утлы
Сулышыннан көя ил җаны.

Ишелә йортлар, хәрабәләр арта,
Сыкрап сызлый җирнең ярасы.
Әле анда, әле монда аунап
Үлеп ята адәм баласы.

...Бик еракта, татар авылында
Йоклый Ана йомшак урында.
Кинәт кенә, тәмле төшен бүлеп,
Дары исе керә борынга.

Сискәнүдән сикереп тора Ана,
Бәргәләнә, сызлый йөрәге.

Газиз улы кайда йөри икән,
Таяныргa бармы терәге?!

Йокысыз төн. Читлектәге коштай
Сизгер күңел ярсып талпына.
Бөркеткәе, канатларын кагып,
Очып киткән таулар ягына.

Таң атса да, Ана күңелендә
Ул көн никтер кояш чыкмады.
Коръән сүрәсе дә басалмады
Җан-бәгырьнең әрнеп сызлавын.

Иртән искән усал җилләр гүя
Каракошның зәһәр сулышы.
Чакрымнарны бер төенгә төйнәп,
Ишек какты Чечен сугышы.

«Югалды ул...» Җилләр пышылдавы
Телгәләде кисеп бәгырьне.
Ялварыплар болытларга дәште:
«Үлсә, кайда балам кабере?!»

Югалды ул... диләр. Ышаналмый
Өмет тулы Ана йөрәге.
Томаннарда эреп югалырлык
Түгел аның ныклы терәге.

Өметен өзми Ана көтә улын,
Үткәннәрдән көтә, бүгеннән.
Гөлләр ята хәтер каберенә,
Шытып чыгып күңел түреннән.

Эзсез кая, кая югалсын ул,
Яши улы һаман йөрәктә.
...Үзәкләрне өзеп, таң алдыннан
Бер кош сайрый кунып тирәккә.

*** * ***

Син киттең дә юкка чыктың, улым,
Нәрсә язган синең тәкъдиргә?
Адашкан кош хәлендәме соң син,
Ятасыңмы салкын кабердә?!

Җилләр дәшми, әллә алар да соң
Белми микән синең хәлеңне.
Кышлар җитсә, тау ягына карап,
Бөркәнәм мин кара шәлемне.

Чечен иле, чәрдәкләнеп беткән
Горур таулар, болыт күзләре,
Бар да күргән кеше сөякләрен
Кимереп йөргән усал этләрне.

Бәлки, син дә... ышанасы килми,
Шул тәкъдиргә дучар булгансың?
Тик шулай да бер кайтырсың кебек,
Җиңеп ачы язмыш буранын.

* * *

Сагынганда тулган айга карыйм,
Ай күзендә синең күзләрең.
Ай нурына сыенып каршылыйм мин
Якынлашкан гомер көзләрен.

Юксынганда татлы сүзләреңне,
Бирелеп тыңлыйм былбыл тавышын,
Былбылларны сайратырлык моңга
Кушып Ходай язган язмышым.

Сандугачлар җырга салган моңнан
Өзелә тагын кемнәр үзәге?!
...Күзгә түгел, йөрәгемә бага
Сагыш тулы дөнья күзләре.

## Көнләшү

Яраланган җанын ялгыз хатын
Ачып салмый һәрбер кешегә.
Ул елмая яшен эчкә йотып,
Ә йөрәге җилдә күшегә.

Көчлелеге белән көчсез дә бит,
Сынатасы килми ятлардан.
Ирле килеш ирсез яшәгәннәр
Көнләшәләр шундый затлардан.

* * *

Җан сусауга түзми, кулларына
Шагыйрь алган каурый каләмен.
Үз халкына әйтер сүзен барлап,
Йөрәк каны белән бизәп яза
Гомер дәфтәренең дәвамын.

* * *

Чык та төшеп өлгермәгән әле
Балачагым баскан эзләргә.
Болын җиле йомшак кулы белән,
Песи баласыдай сырпаланып,
Иркәләнеп сарыла тезләргә.

Шул ук кояш балкый күк йөзендә,
Нурын сирпеп алсу гөлләргә.
Зәңгәр томан булып урала да,
Язмыш булып кабат юрала да,
Сагыш сеңә үткән көннәргә.

Әле яңа ялантәпи басып
Үткән идем яшел чирәмнән.
Кай арада көмеш пәрәвезләр

Соңгы җиле булып җылы җәйнең
Күбәләктәй оча тирәмнән.

Гомер үткән, көзгә кереп барам...
Чык тамчысы минем күзләрдә,
Балачакның якты ал кояшы,
Төсле күбәләкле ямьле җәе
Озата бара алтын көзләргә.

*** * ***

Мәңгелеккә атлар тарихың бар,
Кемнәр килеп, кемнәр китмәгән.
Тик шулай да беркемнең дә гомере,
Авылым, синдә зая үтмәгән.

Яланнарда ерак бабамнарның
Ярылып ята баскан эзләре.
Куҗәкәнең җаны булып бага
Зәңгәр күккә чишмә күзләре.

Ерак бабам, түбәтәен салып,
Тирен сөрткән, эшләп аргачтын.
Онытылган баш киеме бизи
«Түбәтәй тау» булып яр башын.

Мин дә синең туфрагыңа төшеп
Тамыр җәйгән авыл баласы.
Чал тарихка гомерләрне ялгап,
Барасы да әле, барасы...

## Сиңа кайткач

Туган ягым! Чишмәң, күзен ачып,
Сәлам бирә челтер тавыш белән.
Сусавымны басып, дәрман алып,
Үрләреңә, тауларыңа менәм.

Инеш буең куе таллык кына,
Гүя тынлык саклап сакка баскан.
Сөзәк ярның яшел келәмендә
Ромашкалар сары күзен ачкан.

Әрәмәңдә һәрбер куак таныш,
Миңа атап балан төймә тезә.
Сандугачлар, яңа җыр чыгарып,
Моңы белән күңел кылын өзә.

Хозурланып ялгыз тыңлап йөрим
Кәккүкләрнең гомер юраганын.
Тезләнәм дә җиргә, сыйпап алам
Һәр үләнең, һәрбер сырганагың.

Әрем исе татлы сагыш булып
Күңелемә кереп урын ала.
Бертуктамый бәллүр бишегеңдә
Тирбәләм мин – һаман сабый бала.

* * *

Җирем, күгем, газиз илем!
Дәшәм сезгә йөрәк белән:
Нигә сулар кача ярдан,
Ник саргая яшел үлән?!

Чишмәләр дә күзен йома,
Челтерәми саф тавышы.
Әй Илаһым! Бу дөньяның
Кайсы якка авышуы?!

## Тургай җыры

Басуларның йокысыннан
Уянып килгән чоры.
Авыл юлы буйлап кайтам,
Яңгырый тургай җыры.

Сагынып кайтып килешем
Моң тулы тугайларга.
Кычкырып җырлап җибәрәм,
Кушылып тургайларга.

Җанымның сәер чагы шул,
Тургайлы, моңлы чоры.
...Китеп барам авылымнан,
Озата тургай җыры.

## Соңлап килгән мәхәббәт

Син түгел яшьлегем таңында
Тәү таҗын ачучы чәчкәмнең.
Колакта яңгырый бары тик
«Сөеклем» дип назлап дәшкәнең.

Син түгел ачучы тәүге кат
Күңелемнең сихерле капкасын.
Тәү никах пәрдәсен иңбашка
Кадерләп, назлап син япмадың.

Син түгел зөфафым кичендә
Тәнемә кагылды башка яр.
Татлы өн урынына күкрәктән
Сытылып чыкты тик әче зар.

Син түгел сафлыгым татудан
Мизгелгә җуючы һушыңны.
Мәхәббәт патшасы булсаң да,
Язмышлар тик көздә кушылды.

Кагылма сызлаган бәгырьгә,
Тирәнгә уелган җәрәхәт.
Наз түгел, кайчакта йөрәктә

Яралар калдыра мәхәббәт.

«Бердәнбер терәгем» дип, сиңа
Язмаган яшьлектә дәшәргә.
Нишлисең, сагыштан сагышка
Туганмын табынып яшәргә.

Җиңелдем сөюдә димә син,
Назлардан кабынып каршымда.
Бер караш, бер ялкын аша мин
Аңладым барсын да, барсын да.

Яшьлектә ачылган чәчәгем
Сулды шул ятларның куенында.
Бер тамчы тере су бөркесәң,
Елмаеп атлармын каршыңа.

## Уяну

Уф дисәм, авыздан ут чыкты,
Төтене күренде ерактан.
Син булдың кайгыда көлдергән,
Көлгәндә үксетеп елаткан.

Берсүзсез буйсындым мин сиңа,
«Кер» дисәң, кердем ут эченә.
Ышандым, ни генә булса да,
Ялкыннан коткарыр көчеңә.

Ихтыяр ныклыгын сынадың,
Салкын су сиптең син, кабынсам.
Ташлап та, тагып та йөрмәслек
Язмыштан бирелгән муенсам.

Еландай сихерле карашың
Биетте кыздырган табада.
Кылычтай үткен тел, тибрәлеп,
Тоз сипте төзәлмәс ярага.

Ничә ел мин сиңа кол булдым,
Хисләрне санадым сөюгә.
Өзелдем өлгергән җиләктәй,
Карашың тәнемә тиюгә.

Үзең дә күнектең уенга,
Бирмәдең һичкайчан ятларга.
Минем дә уйга да килмәде
Башкага керфегем кагарга.

Газап та, ләззәт тә кичердем,
Ирле дә, ирсез дә тормадым.
Җылытмый башлады җанымны
Ялганнан сырылган юрганың.

Кинәттән ачылды сукыр күз,
Абынып егылгач саламга.

Гайбәткә төренеп, җил керде
Беркөнне безнең дә арага.

Ничә ел буена син мине
Җылыттың үзеңә кирәктә.
Хыянәт пычагы кададың
Мәхәббәт яшәгән йөрәккә.

Җансыз җан адашты аерылып
Вулкандай кайнаган тәнемнән.
Мин беләм, дошман да сөенмәс
Бүгенге аяныч хәлемнән.

Аудым мин җилләрнең куенына,
Сынганга таяныр терәгем.
Аллаһның кодрәте беләндер
Ярылмый түзде бит йөрәгем.

Егылдым аяктан, шулай да
Өметем торгызды кул сузып.
Төн узгач барыбер көн туа,
Таң ата офыкта сызылып.

*** * ***

Язмыштан юралган бәхетне
Ничә ел мин эзләп тилмердем.
Сизми дә калганмын җылысыз
Наз көтеп үткәнен гомернең.

Алданып, адашып айларны,
Елларны сүткәнмен томанда.
Шуңадыр нечкәрде күңелем
Иң нәзек, иң нечкә кылдан да.

Назларга зарыккан бәгырьгә
Тигәндә ятларның куллары
Җанымны көйдерде, әйтерсең
Тәмугның сүрелмәс кузлары.

Ялкында янганда үземне
Юаттым, мин дә бит хатын-кыз.
Җылыга сусаган йөрәккә
Сарылды бары тик салкын боз.

Яшәде миндә гел ике мин:
Берсендә – чишмәдәй пакь күңел.
Берсендә – яралы, сытык җан,
Танымыйм, әйтерсең мин түгел.

Гомернең көзләре җиткәндә,
Башымны ак кырау каплагач,
Төшендем: иң татлы җимешен
Көз бирә бәхетле алмагач.

Суыклар өтсә дә җанымны,
Җиңдем мин икенче минемне.
Биеккә күтәрдем аклыкка,
Пакьлеккә төренгән күңлемне.

* * *

Буш үтмәгән миңа язган гомер,
Булган аның ярсу язлары.
Күңелкәем дөнья гизгән чакта
Сыендырган күпме назларны.

Сөю ялкынына баса-баса,
Менгән чагым булган күкләргә.
Башын җуеп, шашып яратулар
Таныш түгелдер ул күпләргә.

Үз халкыма әйтер сүзләремне
Тезәр өчен шигырь юлына,
Бәхет кошы каләм итеп сузды
Ак каурыен нәфис кулыма.

Күзләрем дә матур, кешеләргә
Тоеп яшим һәрчак кирәгем.
Зая үтми бер көнем дә җирдә,
Тармакланды тормыш тирәгем.

И язмышым! Күпсенмә син миннән
Аклык белән төргән кышларны.
Мәңгелеккә илтер юлны эзлим,
Үз милләтем өчен күңелемдә
Канат ярган шигъри кошларны.

* * *

Гасырларга җитәр җырлар язган
Җәлил елы татар илендә.
Баш очында балта уйнаса да,
Баш имәгән Муса үлемгә.

Үлемсезлек чиген атлаган ул
Туган иле, халкы хакына.
Соңгы сәлам булып җыры кайткан
Ак кылганлы туган ягына.

Җыр онтылмый, гасырларны кичеп,
Мәңгелеккә таба юл ала.
Шагыйрь үлми халкы исән чакта,
Халкы бетсә генә югала.

Яңа гасыр җирдә – Җәлил елы,
Җыр яңгырый татар илендә.
...Шагыйрь исән, чөнки шигырьләре
Яшьнәп яши халкы телендә.

* * *

Түгәрәк диләр дөньяны,
Әллә кителгән чите?
Күктәге кояшның никтер
Каралып тора бите.

Кансызлыкмы, сансызлыкмы,

Шашу микән акылдан?
Әллә инде бу җәмгыять
Үзгәрдеме тамырдан?

Ана булу хокукына
Ия булган хатын-кыз
Яшәр өчен хаклымы соң
Калып намус-калыпсыз?

Фахишәлек чәчәк ата,
Тән сата гүзәл затлар.
Кая тәгәри бу дөнья,
Кешелек кая атлар?

Ун-унике яшендә үк
Гыйффәтен җуйса бала,
Балигъ булып җитешкәнче
Җаныннан өрәк кала.

Мөселманга фарыз булган
Гореф-гадәт югала.
Кыйбласын җуйган кеше
Баткаклыкка юл ала.

Инсафлылык орлыкларын
Туктадыкмы чәчүдән?
Күпме кеше айнымаслык
Сәрхуш булды эчүдән.

Бозыклыкка этәрүче
Коткысымы шайтанның?
Чарасызлык кага бүген
Замананың капкасын.

Намусны да ваклап-ваклап
Сатып бетердек бугай.
Күңелләрдән күңелләргә
Кунып сайрамый тургай.

* * *

Җәбергә, золымга юлыктым
Тормышның катлаулы юлында.
Тик һәрчак өметем кабызган
Ялкынлап янучы шәм булды
Аруны белмәгән кулымда.

Татыдым хыянәт ачысын,
Ничә кат алдандым тормышта.
Ышаныч җуймыйча барыбер
Соң тиен акчамны кайчакта
Суздым мин дусларга бурычка.

Игелек орлыгы туфракка
Күмелсә, шыта ул гөл булып.
Китсәм дә, бу җирдә яшәгән
Гомерем саклансын хәтердә
Мәңгегә өзелмәс җыр булып.

* * *

Бала елый туу мизгелендә,
Яшь аралаш бага дөньяга.
Һәр авазы аша бар җиһанга
Сорау тулы якты моң ага.

Язмышлар да төрле-төрле була,
Буталганы, агы, карасы.
Һәр кешенең якын үз җыры бар,
Һәр йөрәкнең үзгә ярасы.

Ялгышлардан, табышлардан тора
Бу дөньяда кеше язмышы.
Абынганны соңгы көнгә кадәр
Эзәрлекләп бара ялгышы.

Кем адаша яшьлек сукмагында,
Кем адаша җәйләр илендә.
Кемне чөя тормыш биек күккә,
Ә кемнедер төя киледә.

Әхлак үлчәменең берәмлеге
Тайпылганда кинәт читкәрәк,
Бәхет ярмалары сазга төшә,
Калтыранган кулдан тәгәрәп.

* * *

Әллә заман, әллә без гаепле,
Җавап эзли һәркем үзенчә.
Һәркем үзе аңлап бәя бирә
Ни бәһадә намус-төшенчә.

Ахырзаман балаларымы без,
Хаклымы без җирдә яшәргә?
Туа кеше, җиһанга нур сибеп,
Бер булса да балкып яшьнәргә.

Сүнгәннәр бар вакытыннан алда
Аңлый алмый яшәү бәхетен.
Әхлаксызлык кисә бик күпләрнең
Киләчәккә булган өметен.

Иле белән баткаклыкка чумган
Адашканнар каян юл тапсын?
Вөҗдансызлар пычрак кулга алды
Ил-тормышның көйләр тоткасын.

Кесә калынлыгы үлчи бүген
Яшәешнең кадер-кыйммәтен.
Кемнең генә кодрәтеннән килә
Саклап калу илен, милләтен?!

Берләштек без, ничә еллар буе
Милләт белән милләт кушылды.

Маңкорт басты бүген бар дөньяны,
Күтеп алган бәхет шушымы?!
Ата – улны, ана кызны белми,
Бар да сата, бар да сатыла.
Акылларын җуйган күпме җаннар
Сүнгән йолдыз булып атыла.

Чирле җәмгыятьтә чарасызлык –
Котылгысыз элмәк кешегә.
Күпме җаннар бүген җылы эзли,
Күпме җаннар өши, күшегә?

Наз эзлиләр, җылынырлык учак,
Җылынырлык кочак эзлиләр.
Заман томанында әлсерәшеп,
Чыгар сукмак сайлый күзлеләр.

Күңел күзе сукырларга күптән
Калган инде диңгез тубыктан.
Андыйларның вөҗдан көзгеләре
Тора тоташ соры тутыктан.

Ата-ана, бала хакын хаклап
Яшәүчеләре дә бик сирәк.
Ватык сәгать кебек көйсезләнеп,
Күкрәкләрдә тибә буш йөрәк.

Орлыклары кипте игелекнең,
Кимеп бетте үрчер шытымы.
Җен-пәриләр өере алыштырды
Әйтерсең лә кеше токымын.
Алтын-көмеш, ялтыравык күлмәк,
Затлы туннар ябып өстенә,
Шәрәләнде җаннар. Тармаклары
Коргаксыган тамыр төсендә.

Шашты дөнья, шашты бар кешелек,
Шашты кызлар, шашты егетләр.
Әфьюн сөременә томаланып,
Аяк сузды якты өметләр.

Тормышыннан арып туйганнары
Баштанаяк чумды хәмергә.
Бер минутлык теләк буйсындырды
Җанны-тәнне аңсыз әмергә.

Убыр чире йоктыргандыр, ахры,
Авылларны йота калалар.
Әхлаксызлык чәчәк ата җирдә,
Уйнаш уйнап туа балалар.

Елап туа бала, сорау белән,
Яшәрбезме берәр кешечә?!
Һәркем үзе аңлап бәя бирсен
Ни бәһадә намус-төшенчә.

* * *

Тау артыннан биек тауга мендең,
Баса-баса кеше башына.
Уйламадың үзем йотармын дип,
Төкергәндә кеше ашына.

Мөнбәрләргә басып нотык тоттың,
Тел чарланган синең күптәннән.
Тик күрмәдең, нурсыз күзләреңә
Күпме рәнҗеш бага үткәннән.

Намус белән дөнья кичәм, дидең,
Тел сөйли шул, ул бит сөяксез.
Кеше җанын кискәләргә туган,
Теткәләргә туган көя сез.

Шулай тиеш, мин бит бөек, диеп
Инангандыр, бәлки, күңелең.
...Гомер көзләрендә ач кандала
Булып ялгыз үтә гомерең.

## Юлчы

Мин сусаудан яралганмын, ахры,
Сусап яшим туган мизгелдән.
Җирси күңел, чүлдән чишмә эзләп,
Аерылгач туган нигездән.

Мин сөюдән яралганмын, ахры,
Сөю-назга сусый күңелем.
Мин – мәңгелек сәфәрдәге юлчы,
Сөю эзләп үтә гомерем.

## Йөрәгемә яфрак сыена

Быел никтер иртә килде көзләр,
Юлларыма яфрак коела,
Юатыр дип өмет иткән төсле,
Иңнәремә килеп сыена.

Гомерләрнең бер көне – бер яфрак,
Өзелеп төшкән инде күпмесе?!
Сукмак буйларында кала тезелеп
Сары яфрак – сагыш билгесе.

Сагыш сукмагында ялгыз каен,
Җил искәндә яфрак коела,
Юатыр дип өмет иткән төсле,
Йөрәгемә килеп сыена.

## Песнәк

Әллә ризык, әллә җылы эзләп,
Тәрәз каршысына кунды песнәк.

Уйга калдым шул кошчыкка карап,
Сүзсез генә, иренемне тешләп.

Бу кошчыккай ни әйтергә тели,
Нинди моң соң песнәк күзләрендә?
Инде тиздән салкын кышлар килер,
Шикләнәме әллә түзәренә?!

Тагын бер гамь артты йөрәгемдә...

## Кыш көткәндә

Табигатьне иңли кыш сулышы,
Яфракларны сары моң сарган.
Сузылыплар җирдә сагыш ята,
Ак кышларны көтеп җир арган.

Озын булды быел көз мәлләре,
Җир йөрәге сызлый торгандыр.
Күңелемдә хисләр өермәсе –
Килә алмаган кышта бурандыр.

## * * *

Бар табигать кышны көтә
Соңлап килгән көз мәлендә.
Күксел болыт, шәрә агач,
Күшеккән кош җир өстендә.
Усал җилләр урам буйлап
Яфракларны куып йөри.
Табигатьтә бер эше юк,
Йөрәктәге утлы күмер
Ялкынланып янар өчен
Өмет сирпеп һаман көйри.

## * * *

Ала карга төсле туң җир,
Өшегәнме, күшеккәнме?!
Көтеп ята сүзсез генә
Ап-ак кардан сарган юрган
Кендегенә берекәнне.

## Җавап эзлим

Тагын кайтты илгә цинк табут,
Кемнәрнеңдер газиз баласы.
Ять-яшь килеш җаннар кыелганда
Ничек итеп тыныч каласы?!

Үстерәбез күз карасы кебек,
Озатабыз илне сакларга.
Ә ни өчен илнең көче җитми
Кайгылардан безне якларга?

Ятим итеп, җанга яра салып,

Рәнҗеп китә газиз балалар.
Кара хәбәр ишетелгән саен,
Күз яшьләрен түгә аналар.

Өмет утын кем кабызыр миндә?
Шул сорауга җавап эзлимен.
Илгә кайтты тагын цинк табут,
Күз яшьләрен түгәм, түзмимен.

## Ятим бакча

Пар каенны кисеп төшерделәр,
Телем-телем телеп йөрәкне.
Ятим калды бакча пар каенсыз,
Җуйган төсле соңгы терәкне.

Тораташтай басып сүзсез калдым,
Каен ауды, ауды терәгем.
Пар каеннар үлде кочаклашып,
Ничек түзде икән йөрәгем?!

Тәрәз төбем бизәп, язгы таңда
Исмәс инде каен җилләре.
Пар каеннар алып китте кышта
Үзе генә белгән серләрне.

## Уйлану

Анам миңа яшәр өчен гомер бирде,
Туган җирем күңелемә моңын үрде.
Тәүге язлар алып килде якты сөю,
Сөю белән бергә күктән бәхет иңде.

Акыл белән хис сугышты гомер буе,
Сөю өчен суга кердем, утта яндым.
Һәм, ни гаҗәп, гомеремнең көзләрендә
Сагыш тулы күңел белән ялгыз калдым.

Беркатлымы, әллә артык горур булдым,
Нидә икән минем гаеп? Юк җавабым.
Шуны беләм: җиргә килгәч китү дә бар,
Әҗәл белән уртаклашып җан газабын.

## Туңган чия

Туңган чия куйдың алларыма,
Җәй китерим диеп күңелгә.
Мин дә бүген туңган чия төсле,
Күзләремнән сагыш түгелә.

Туңган чия эри учларымда,
Син елмаеп миңа карыйсың,

Әйтерсең лә, туңган чия кебек,
Җанда ниләр барын аңлыйсың.

Кысып кочсаң бер мизгелдә минем
Туңган җаным эрер кочакта.
Пешкән чия булып иреннәрем
Үрелерләр сиңа шул чакта.

## Сиреньнәр

Назга сусап арган зифа буйны
Көчле куллар алды кочакка.
Тетрәнде җан, килеп эләккәндәй
Дөрләп янган кайнар учакка.

Утлы караш сихерләде кинәт,
Тукталгандай булды йөрәге.
Шуып төште йомры иңбашыннан
Тәнгә ятып торган күлмәге.

– Җаным минем, бердәнберем! – диеп
Кабатлыйлар кайнар иреннәр.
Тәрәз каршысында, хуш ис бөркеп,
Оялышып тора сиреньнәр.

## Балан

Алып кайтты язмыш кабат мине
Яшьлек язым калган аланга.
Карап торам исем китеп уттай
Янып пешкән кызыл баланга.

Балан тәлгәшләре, сыгылып-сыгылып,
Әйтерсең лә түгә күз яшен.
– Ниләр булды, канлы яшьләр түгеп
Ник елыйсың? – диеп эндәштем.

Минем кебек түзем җанлы балан,
Хәсрәтләрен җыйган тәлгәшкә.
– Түз! – дигәнгә башын аска иеп,
Колак салып калды киңәшкә.

## Күзләр килә

Әйтер сүзләремне барлый-барлый,
Еллар буе көтеп яшәдем.
Табигатькә кабат күзләр килде,
Коеп гөлнең алсу чәчәген.

Ялгыш кына ятлар кулы тисә
Наз-сөюләр көткән тәнемә,
Аңламаслар минем халәтемне,
Кералмаслар минем хәлемә.

Гомер буе җылы назлар көтеп,
Зур сөюне көтеп яшәдем.
Әкрен генә атлап көзләр килә,

Күңелемнең коеп чәчәгеn.

## Түз, йөрәгем!

Тормыш диңгезендә йөзгән чакта,
Актарылып менә дулкыннар.
Ахыргача йөзеп чыгар өчен
Кемнәрдә көч, бетмәс дәрман бар?

Тешен кысып, куйган максатына
Ирешергә күпләр тырыша.
Андыйларга хәтта давыллар да
Буйсыналар икән тормышта.

Көчле рухлы, түзем җаннар гына
Кичеп чыга тормыш диңгезен.
Әйтерсең лә гомер атының ул
Кулларына алган тезгенен.

Күз карасы җитмәс киң диңгездә
Кораб булып алга йөзәмен.
Ахыргача сынмый яшәр өчен
Сынатмыйча түз син, йөрәгем!

*** * ***

Алиһәдәй чибәр, садә кызым –
Яшьлегемнең гүзәл өлгесе.
Ак ефәктәй чәчле газиз Әнкәм –
Килер картлыгымның көзгесе.

Кызыма күз салсам, чая яшьлек
Кабат кайткан кебек тоела.
Әнкәемә баксам, киләчәгем
Күңелемә килеп сыена.

Яшьлек белән аерырга теләп,
Сагыш шәлен яба иңемә.
Җыерчыклы кулны сыйпап, сөеп,
Кереп киләм көзләр иленә.

*** * ***

Нәрсә кала миннән, китә калсам
Саубуллашып якты дөньядан?
Ике балам – минем дәвам булса,
Мин ышанам, эзсез югалмам.

Яшәү өчен гомер бүләк иттем,
Яшьлек төсем – кызым, улыма.
Үкенечкә түгел, үткән гомер
Якты бер юл булып сузылса.

*** * ***

Дөреслекнең йөзе нинди була?
Балкый микән якты кояш төсле,
Әллә инде чагыла дөньялыкның

Гасырлардан җыйган сагыш төсе?!
Дөреслекнең тәме нинди була?
Татлыракмы пешкән алмалардан,
Әллә инде бөтен дөньялыкның
Хәсрәт ачыларын җыеп алган?!
Дөреслекне табып була микән?..
Дөреслекне танып була микән?..

* * *

Үлчәп булмый микъдарларда
Яратуның серле көчен.
Мин сөюдән яралганмын,
Сөелер һәм сөяр өчен.

Үлчәп булмый чакрымнарда
Озынлыгын гомерләрнең.
Яши-яши төшенәсең
Мизгелләрнең кадерләрен.

Үлчәп булмый бәхетләрне
Бизмәннәргә салып һич тә.
Минем бәхет миндә яши,
Үз җанымда булган көчтә.

* * *

Чиксез галәм киңлегендә
Һәммәбезгә үзгә дөнья.
Җиргә басып йөрсәк тә без,
Җир язмышы безнең кулда.

Беләбезме кадерләрен
Ходай биргән бу бәхетнең,
Үз кулыбыз белән әллә
Уябызмы җир-ләхетне?!

Тынып тормый гасырлардан
Гасырларга сугыш уты.
Яна-яна ярлылана
Бар халыкның уртак йорты.

Адашырлык урманнар юк,
Уңдырышсыз кырлар арта.
Муенына элмәк салып,
Һәр замана бавын тарта.

Кешелекнең кулларында
Җир-ананың җаны көйри.
...Гамьсез кеше берни күрми,
Җиргә ныклап басып йөри.

## Адашкан җаннар

Юлын тапмый йөри җиһан буйлап,
Кыйбла җуйган һәм адашкан җаннар.
Милләт белән милләт кушылуы

Томаланумы ул аек аңнар?

Катнаш гаиләдә туган бала
Тарткаланып үсә ике якка.
Балигъ түгел, маңкорт хәлендә ул
Бәргәләнеп басып тора чатта.

Урыс побы аны чукындырды,
Татарлыгы бары сөннәтендә.
Имансызлык чәчәк аткан чорда
Сыенсын ул кайсы милләтенә?!

Йөрәккәе нигә телгәләнә,
Туганчы ук кемнән ул каргалган?!
Татармы ул, әллә урыс микән,
Иманмы соң җанда, әллә ялган?!

Ахырзаман баласымы соң ул,
Кемнәр аңа шундый тозак корган.
Кискәләнгән җаны юл чатында
Бар көченә сала бүген оран.

Дәшә җаны галәм киңлегенә,
Җирдә аны юк, юк, ишетмиләр.
Кемгә генә барып сыенса да,
Танымыйлар аны, иш итмиләр.
Кискәләнгән татар гәүдәсеннән
Яралгандыр, ахры, аның җаны.
Татарлыгын юып ала-ала,
Тамырлардан ага урыс каны.

*** * ***

Мин дә Тукай, Җәлилләрне биргән
Бөек халык – Татар баласы.
Сөендерә якты киләчәге
Һәм әрнетә йөрәк ярасы.

Заманалар, сандалларга салып
Чүкесә дә, бөгә алмаган.
Рухи ныклык татар кавеменең
Язмышына бүләк Алладан.

Горурланам. Мин дә Туфаннары,
Такташлары булган милләттән.
Үз телем бар аралашыр өчен,
Үз моңым бар көйләр көйләткән.

Балаларым үз телендә сөйли,
Үз телендә җырлый җырларны.
Халкым исән, яши, яшәр, беләм,
Кичеп гасыр, кичеп чорларны.

## Сандугач

Тал тирәккә кунып сайрый
Бер кош һәр көн, таң тугач,
Әйтерсең лә һәр күңелдә
Яши сары сандугач.

Һәр йөрәкнең үз ярасы,
Һәр кошның бар үз моңы.
Һәр кешенең язмышында
Тәкъдир язган үз юлы.

Кошка – тирәк, җанга йөрәк
Кирәк гомер итәргә.
Сусаганда, чишмә булсын
Ятып суын эчәргә.

Кем ярасын кем дәвалар,
Җанга тоташ моң тулгач.
Җиргә килгән һәрбер кеше
Ул – яралы сандугач.

*** * ***

Күз сирпү дә җитә, кай күңелнең
Ишекләре шундук ачыла.
Бер-береңә әйтер ихлас сүзләр
Җылы назлар булып агыла.

Ике куллап кайчак шакысаң да,
Ачылмаган ишек табыла.
Битарафлык җиле, суык өреп,
Җан-бәгырьгә килеп кагыла.

## Минем күңел

Минем күңел көзге көнгә охшаш –
Кояш, бер карасаң, елмая,
Бер карасаң, тулган болыт булып
Яшен түгә якты дөньяга.

Минем күңел көзге урман төсле –
Яфрак коя җилләр искәндә:
Әллә инде язны юксынганга,
Әллә яшьлек искә төшкәндә.

Минем күңел тирән күлгә охшаш –
Тигез түгел күлнең өсләре.
Аккошлары киткән күл күзендә
Чагыла көзнең барлык төсләре.

## Хәтер йомгагы

Утырдым мин йон эрләргә,
Сердәшем юкә кабам.
Җеп эрли җитез кулларым,
Уйларга юллар салам.

Уй йомгагын сүтү, бәлки,
Сузылыр айга, елга.
Хәтер сандыгын актарсаң,
Кузгала бозлы елга.

Актарылып ага уйлар,
Гүя боз кантарлары.
Чүплим эзләп арасыннан
Кадерле янтарьларны.

Булган ваемсыз балачак,
Бәхетле мизгелләрем,
Булган ычкынган чаклары
Кулдагы тезгеннәрнең.

Хәтердә калган уелып
Яшьлектә сөйгән ярлар,
Чайкалып көчле дулкыннар,
Ишелгән серле ярлар,

Очкынланып янган чагым
Мәхәббәт учагында,
Наздан эрегән мизгелләр
Хәләлем кочагында,
Тәү мәртәбә назлап кулга
Сабыем алган минут,
Күкрәк сөтен татыганда
Кичергән серле тынлык.

Парым булган бозлы елга,
Мин – дөрләп янган учак.
Язмыш аерган мизгелләр
Сыналыр һәм сынар чак.

Су белән ут берекмәдек,
Җимерелде хыяллар.
Арабызда граниттай
Үсеп чыкты кыялар.

Булган зурлаган чакларым
Дус санап дошманнарны.
Күңел түренә утырган
Узганның юшкыннары.

Булган күктән эзләгәнне
Җирдән тапкан чакларым,
Татыганым җан сызлаткан
Боз кочагын ятларның.

Булды гамьсезләрне күреп
Чарасыз калган минут,
Бер җылы сүз ишетүгә,
Елаган күңел тулып.

Тансыклаган җан җылысын
Туңганнарга биргәнем,
Үкси-үкси елар чакта
Кычкырыплар көлгәнем.
Булды йолдызга үрелеп

Балкыган мизгелләрем,
Каләмемне канга манып,
Шигырьгә түгелгәнем.

Үкенерлек түгел язмыш,
Бәхетлерәк күпләрдән.
Сыгылмый яшәр көч таптым
Тормыш салган йөкләрдән.

Юкә кабага утырдым,
Йон эрли җитез кулым.
Мин бәйләгән оекбашлар
Моң тулы гомер юлым.

## Шагыйрь җаны

Давыллардан халкын яклар өчен,
Кулга каләм тоткан.
Шагыйрь йөрәгендә мизгел саен
Тетрәп тора вулкан.

Язмышына илнең борчылганда,
Өши кайнар каны.
Ак каләме язган шигырьләрдә
Яши шагыйрь җаны.

## Эз

Туа кеше, әкрен генә
Офыкка таба бара.
Нәни генә йөрәгенә
Сыйдыра меңәр яра.

Уза гомер, сизелми дә,
Су кебек китә агып.
Күңел яшь килеш калса да,
Барыбер килә картлык.

Шагыйрь яши янып-көеп,
Киткәндә кала сүзе.
...Тагын бер йолдыз атылды,
Сызылып калды эзе.

## * * *

Ничәмә кат сынаса да язмыш,
Хәлсезләнеп җиргә чүкмәдем.
Ә шулай да булды, сузылып ятып,
Басып торган җирне үпкәнем.

Дөньяларны иңләп чыгалмадым,
Диңгезләр дә әле кичмәдем.
Ә шулай да җирнең күзләреннән
Булды ятып ширбәт эчкәнем.

Җирдә туып, җирдә үстем бит мин,

Җиргә бәйле бөтен язмышым.
Тамырларым илем туфрагында,
Тоеп яшим җирнең сулышын.

* * *

Бурычларым бик күп, түли алмыйм,
Һаман кысан вакыт кысасы.
Җан сызлаган бу мизгелдә килә
Дөньялыкны кысып кочасы.

Күңел бай да, кемгә кирәге бар,
Кемнәр мохтаҗ андый байлыкка?!
Нәрсә соң ул синең язган шигырь
Ил сатып көн күргән халыкка?!

Илен, динен, үз милләтен саткан
Аңлыймы соң күңел халәтен?!
Ә мин, тиле, көтеп яшим җирдә
Сугар диеп шагыйрь сәгате.

Бер күрерләр әле, ишетерләр
Җанны ярып чыккан сүзләрне.
Үз халкыма булган бурычларым
Карый булып вөҗдан күзләре.

* * *

Күп вакытта ашыгабыз бугай
Сүтәр өчен гомер йомгагын.
Кай арада сизелми дә үткән
Алтынга тиң яшьлек елларым.

Тик яратып туялмадым әле,
Назлар тулы минем күңелем.
Башкаларга әйтер сүзләрем бар,
Өзелгәнче җебе гомернең.
Туймаганмын әле яратылып,
Назга сусый һаман йөрәгем.
Яшен кебек яшьнәп яшисем бар,
Кешеләргә тоеп кирәгем.

* * *

Чыр-чу килеп бала-чага уйный,
Сибелгәннәр чәчәк шикелле.
Агач атта чапкан малайларның
Кояш сыман җирән сипкеле.

Утыргычта түбәтәйле бабай,
Сабыйлыкка күңел тартыла.
Атлана да якты хыялында
Иярләгән ярсу атына,

Урамнарга сыймый, яланаяк
Күңел чаба узып картлыкны.
Керфек очларында энҗе бөртек –
Картлыктагы сабый шатлыгы.

* * *

Кышлау карны җилләр ялап ала,
Ала-кола инде җир өсте.
Аяк асты тулы күлдәвекләр,
Яз сулышы булып наз исте.

Күз камаша язгы яктылыктан,
Бар җиһанда гүзәл манзара.
Ил-көнемә изге дога укый
Мәчеттәге айлы манара.

* * *

Яз сулышын сизә күңел,
Чыңлап куя һәрбер кылы.
Әйтерсең лә сизгер җаннар
Аша үтә язның юлы.

Яз сулышын тойган мәлдә
Умырзая калка җанда.
Өзлеп-өзлеп былбыл сайрый
Күңелдәге бөдрә талда.

Әле җирдә ак кар ята,
Уянмаган гөрләвекләр.
Җанда гына җәйрәп ята
Көмеш күзле күлдәвекләр.

Әле җирдә ак кар ята...

* * *

Ишетәсезме, кошлар шашып сайрый,
Сөенешеп язлар килүенә.
Мин дә бүген гаҗәпләнеп карыйм
Нур эчендә тамчы биюенә.

Дөнья кинәт яктырыплар китте,
Тетрәнүгә бөре керфекләре.
Алларыма энҗе булып ява
Язгы яңгыр – ләйсән бөртекләре.

* * *

Язгы җилләр каен кызын үбә,
Наз бишеккә салып тирбәтә.
Куанычтан шашып сайрый тургай
Күктә түгел, ярсу йөрәктә.

Яңара һәм матурлана дөнья,
Җанны назлый кояш нурлары.
Гөрләвекләр юып юкарталар
Кардан сырган мамык юрганны.

Дәртле тамчы бии, шатлыгыннан
Чыпчыкның да җыры үзгәрәк.
Күңелләргә кунды, канат җилпеп,

Яз исемле төсле күбәләк.

* * *

Бөреләр, кысып күзләрен,
Карый кояш йөзенә.
Ак күлмәкле каен кызы
Үзен күзли көзгедән.

Чәчен таратып салган да
Иркә җил куенына,
Болыт-яулык урап куйган
Зифа төз муенына.

Табигатьнең яз сулышын
Иснәп исергән чагы.
...Туң йөрәкне дә эретә
Язның кайнар кочагы.

## Язгы җыр

Бозланды, йөрәк бозланды,
Эремәс дигән идем.
Иелә белмәс башымны
Түбәнгә игән идем.

Йөрәктәге кар-бозларны
Эретте кояш нуры.
Җылы нурлар белән керде
Йөрәккә сөю җыры.

Таралды сагыш болыты,
Язгы җил тәрәз какты.
Дөньяга үзгә ямь өстәп,
Гөлләрем чәчәк атты.

## Мизгел

Ак каеннар, башын иеп,
Искән җилдә чәчен тарый.
Урман-йортта, юмартланып,
Кәккүк безгә гомер саный.

Бу илаһи гүзәл мизгел
Язлар саен кабатлана.
Һәрбер куак кошка – тәхет,
Мәхәббәтен аңлатканда.

## Дәртле тамчы

Бар дөньяны сафландырып
Ява шифалы яңгыр.
Гөлләр кояшка үрелә,
Тирәнгә китә тамыр.

Әйтерсең лә җәйге болыт

Шатлыктан түгә яшен.
Дәртле тамчы и тыпырдый,
Телгәли күкне яшен.

Сулар сулыш иркенәеп,
Яшисе килеп китә.
Ал кояш, болыт аралаш,
Яшьле күзләрен сөртә.

* * *

Кызган җиргә бии-бии,
И яуды яңгыр-тамчы.
Дымга сусап сулган гөлләр
Елмаеп күзен ачты.

Хушланды дөнья, сафланды,
Пар күтәрелә җирдән.
Җыелып калды күлдәвек,
Көрәйде яшел чирәм.

Кошлар сайраша сөенеп,
Чыланды каен шәле.
Шәл чугыннан тамчы тама,
Һавада яңгыр тәме.

## Болыт мендәре

Җилләр исә, дымлы җилләр
Яңгыр алып киләдер.
Яргаланып беткән җирем
Тиздән суга кинәнер.

Баш калкытыр сулган гөлләр,
Балкып китәр бар дөнья.
Сайрар кошлар берөзлексез
Моң чәчәр уңга, сулга.

Ә хәзергә талгын гына
Исә яңгыр җилләре.
Күк йөзендә катлы-катлы
Күксел болыт мендәре.

## Көзге аһәң

Бер болыт юк. Чалт аяз күк йөзе.
Алма исе килә һавада.
Алтын келәм түшәп сукмакларга,
Әкрен генә сагыш-моң ява.

Төньяк-көнчыгыштан искән җилдән
Кышның тын алганы сизелә.
Көз гомере бетеп килә инде,
Яфрак булып җаны өзелә.

* * *

Көзләрнең дә була аяз көне,
Була яңгыр, була карлары.
Үрсәләнеп искән җилгә сибелә
Каеннарның моң һәм зарлары.

Соңгы яфрак әҗәл куенында
Бирешмәскә теләп тартыша.
...Ә дөньялык, салмак кына атлап,
Аяк баса салкын ак кышка.

* * *

Утлы чәчкә булып кышта
Көйләр өчен тормыш җырын,
Миләшкәйләр тәлгәшенә
Җыя икән кояш нурын.

Һәр бөртектә нәни кояш
Чем-аклыкка нурын сибә.
Салкын җилләр дулап иссә,
Карга чәчелә кызыл төймә.

## Каен зары

Тәлгәш-тәлгәш сары чугын болгап,
Сөйли каен зарын-сагышын.
Сизми калган икән сылукай да
Узып барган гомер агышын.

Сары яфрак өзелә дә җилдә,
Сыенырга эзли терәген.
Урын таба алмый, авырттырып
Тибеп куйды кинәт йөрәгем.

## Көз

Елга буе моңсуланган инде,
Сизелми дә кебек агышы.
Кыйгак-кыйгак кыр казлары китә,
Чит җирләргә куа язмышы.

Көзге урман. Гөмбә исе тулган.
Өрәңгегә ялкын-ут капкан.
Сары төскә манып бар дөньяны,
Җиргә сузылып сагыш-моң яткан.

* * *

Җаным яна. Күзләремнән
Сибелеп җиргә тама очкын.
Чишелмәгән табышмактай
Сергә кушыла яңа тылсым.

Чыга бөркеп утлы чәчәк,
Җанны ялмап давыл куба.

...Яфракларга ялкын капкан,
Шәүләләре уйный суда.

## Соң

Сүнеп бетеп килә соңгы шәме
Яз китергән олы мәхәббәтнең.
Төзәтүләр мөмкин түгел икән
Йөрәктәге тирән җәрәхәтен.
Соң шул инде...

Хыянәтең агулы ук булып
Мәхәббәтнең йөрәгенә тиде.
Соңгы яфрак кебек бөтерелеп,
Сөюебез янган утта көйде.
Соң бит инде...

## Өзелгән җыр

Ләйсәнгә тиңләдем
Мин синең назларны.
Көзләргә алыштың
Чәчәкле язларны.

Җанымның ярасын
Төзәтим ничекләр?!
Мәхәббәт каршында
Ябылды ишекләр.

Саргаймый коелды
Яфрагы каенның.
Суларга салыйммы
Яртысын кайгымның?

Төзәлмәс мәңгегә
Җандагы җәрәхәт.
Өзелгән җыр кебек
Сагышлы мәхәббәт.

## Учак

Нишләдек без?! Кемдә күбрәк гаеп?
Якты язда учак кабыздык.
Кабыздык та очкынланып янган
Учакны без салда агыздык.

Елга уртасыннан агып китте
Дөрләп янган сөю учагы.
Икебезне ике якка этеп
Җибәрде бит язмыш кочагы.

Син бер ярда, мин икенче ярда
Карап калдык сөю артыннан.
Бер ялгышлык аерып куя икән
Тәкъдирләрдә язган артыңнан.

Агып китте салда безнең сөю,
Соң аңладык ятим иткәнен.
Сүнгән учакларның көле булып
Карап тора ярда үткәнем.

* * *

Сакламадык. Сөю хакын хакламадык.
Сүнде учак. Ялкынланып янмас бүтән.
Сине – миңа, мине сиңа китерүче
Сукмакларга буран калын карлар өйгән.
Синең җаның – миннән, ә минеке синнән
Мәңгелеккә бизгән. Уртак сөю үлгән.
Сакламадык. Сөю хакын хакламадык...

## Пар алма

Алмагачның пар алмасы идек,
Тигез парлар идек ул чакта,
Ләйлә-Мәҗнүн булып икәү бергә
Оҗмах ишекләрен ачканда.

Күз тидеме безнең зур сөюгә,
Язмыш безне никтер аерды,
Син язларда калдың минсез генә,
Мин көзләргә атлыйм аеры.

Ә мәхәббәт калды урталыкта,
Үпкәләттек бугай без аны.
Шуңа микән сары сагыш сарды
Сөюләрсез калган дөньямны.

Сөю илендәге алмагачның
Пар алмасын кемнәр татыды?!
Сагынып яшим шул алмалар төсле
Бәхетле һәм парлы чагымны.

Түм-түгәрәк түгел бәхеткәем,
Тешләп алган алма шикелле.
Җанда – яра, багалмамны кабат
Табалуым инде икеле.

## Яратасым килә

Җилләр булып сиңа пышылдыйм мин,
Ишетәсең микән сүземне?!
Бар дөньяңны оныттырыр итеп
Яратасым килә үзеңне.

Уттан алып суга сала торган
Мизгелләр дә була гомердә.
Синең җанда учак кабызырга
Әйләнимме утлы күмергә?!

* * *

Назлардан югалттым башымны,
Шайтанның коткысы көчлеме?
Языкмы, бүләкме язмыштан,
Өнемме, әллә соң төшемме?!

Таң атып килгәндә, син дә мин
Гөнаһның куенына атылдык.
Тотмады итәктән нигәдер
Елларда сыналган сабырлык.

Этәрдең җанымны упкынга,
Булдымы ныклыкка сынавың...
Үкенмим, шул мизгел басты күк
Җанымның җылыга сусавын.

## Бәхет төне

Хәтереңдәме, әллә оныттыңмы,
Исеңдәме уртак бәхет төне?
Саклыйсыңмы син дә йөрәгеңдә
Зур җиһанга сыймас татлы серне?

Төн уртасы. Тәрәзәмне кага
Өмет җиле, бәлки, сары көздер?..
Төштәме соң, әллә өндә булды
Наздан шашкан, акыл җуйган мизгел?

Чынбарлыкмы, әллә инде мәңге
Чынга ашмас татлы хыял иде?
Йөрәгемнең иң түрендә яши
Язмыш безгә биргән бәхет төне.

## Сөю алмалары

Соң очраштык. Соңлап туганмын мин.
Синең язмыш башка белән бәйле.
Учларыма кызыл алма салдың,
Иренемдә әче әрем тәме.

Соң очраштык. Тәкъдир шулай язган.
Син кочакта түгел, йөрәгемдә.
Мизгел түгел, гомер кичәр өчен
Уралдым мин синең серләреңә.

Соң очраштык. Ярый әле Ходай
Соң булса да безне табыштырган.
Син булмасаң, сөю алмаларын
Алыр идем кемнең кулларыннан.

* * *

Мин төшемдә Казан ханлыгына
Сәфәр кылган. Серле мизгелдә
Баштанаяк чумдым ярсып торган
Сөю хисләр тулы диңгезгә.

Сихри кичтә язмыш кушты безне.
Син Хан анда, ә мин Ханбикә.
Кулга-кул тотынган тиң ярларны
Хис дулкыны чөйде биеккә.

Безнең җаннар бергә тоташканга
Шаһит булды Казан каласы.
Пәһлевандай ирнең кочагында
Калтыранды болан баласы.

## Тылсымлы көй

Кайнар сулышыңны тойган чакта,
Һәр күзәнәк тәндә уяна.
Шашкын хисләр диңгезенә салып
Тирбәтәсең татлы хыялда.

Син – гармунчы, ә мин – гармун теле,
Тылсымлы көй – безнең мәхәббәт.
Акылларны җуйдырырлык мизгел,
Җанда сөю, җанда мең ләззәт.

Ике ялкын бер учактай янсын,
Сүрелмәсен иде гомергә.
Бәхет тәмен татып китәр өчен
Кавышканбыз икән без җирдә.

## Җанда кабынган учак

Наз илендә без икебез.
Алма кебек бербөтен.
Ачтык бүген дөньялыкның
Өр-яңа чиста битен.

Йөрәкләр бер булып тибә,
Кулымда синең кулың.
Икәү бергә язабыз без
Сөюнең яңа җырын.

Җиде кат күк өсләренә
Чөйде сөю вулканы.
Көйдерә утлы кузлары
Назларга туймас җанны.

Күкләр бирде бу бәхетне
Өлешләп түгел, көрәп.
Мәхәббәт тавына мендек,
Иңне иңнәргә терәп.

Җәннәтләргә ишек ачты
Назга төренгән кочак.
Мәңге янар сүрелмичә
Җанда кабынган учак.

## Сөю хисе

Без бербөтен. Бу бит гөнаһ түгел.
Мәхәббәтне күкләр иңдергән.
Без генәме әллә бу дөньяда
Шашкын хистән шулай тилергән?!

Адәм белән Һава яратышкан,
Авыз иткәч җәннәт алмасын.
Бездән соң да тормыш дәвам итәр,
Үкенечкә гомер калмасын.

Мәңгелеккә безне озатучы
Сөю хисе җиңәр үлемне.
Яшәтерлек, яшәртерлек итеп
Яратырмын һәрчак үзеңне.

## Болыт

Болытлар да күңел кошы сыман,
Арадашчы итик аларны.
Көн дә күкне гизгән хәбәрчеләр
Якынайтсын безнең араны.

Ак болытлар елмаюым булса,
Күксел болыт сагыну-сагышым.
Тып-тып тамса яңгыр, хәтерләтер
Ярсу йөрәгемнең тавышын.

Мин, сагынсам, болытларга карыйм,
Сәлам юллап синең тарафка.
...Синнән килгән болыт эленеп калган
Өй янында үскән наратка.

## Яныйк әле

Син – тоташ наз, мин – тоташ моң,
Кабатланмый торган җыр.
Бу янулар дөньялыкта,
Бәлки, соңгы янудыр.

Бәлки, яшьлеккә кайтудыр,
Яңадан кабынудыр.
Минсез үткән, синсез үткән
Елларны сагынудыр.

Яныйк әле, дөрләп яныйк,
Кемнәр янып китмәгән.
Синдә наз бар, миндә наз бар,
Димәк, язлар үтмәгән.

Бәхет диңгезен кичәрлек
Дәрман бездә бетмәгән.
Сагышлардан саргайтучы
Күзләр әле җитмәгән.

Янып калыйк тагын бер кат
Без сөю учагында.
Син – тоташ наз, мин – тоташ моң,

Тирбәләм кочагыңда.

## Утлы җимеш

Тәлгәш-тәлгәш миләшләрне
Алларыма өзеп салдың.
Уттай сәйләннәргә карап,
Бер мизгелгә өнсез калдым.

Ни әйтергә теләдең син,
Күңелеңдә ниләр иде?
Миләшләрнең әчелеге
Сагыш булып җанга тиде.

Хәтеремә сеңеп калды
Синең караш моңсу килеш.
Эзләреңә яфрак ява,
Учларымда – утлы җимеш.

## * * *

Утта янган чаклар бик күп булды,
Ялкын өтте күңел канатын.
Таулга менгән чакта, егылып төшеп,
Йөрәгемне ничә канаттым.

Син очрадың язмыш сукмагында,
Дәвалады җылы карашың.
Көч өстәдең хәлсез йөрәгемә
Узар өчен җәй-көз арасын.

Хәзер янам сөю утларында,
Янган саен килә яшисе.
Чиксез мәхәббәттә яшәү тәме,
Саф хисләрдән килә яшь исе.
Соң түгел бит, әле соң түгел дип
Юатабыз икәү күңелне.
Тоташ утта янып бетмәс өчен
Чикләп биргән Ходай гомерне.

## Тезләнерсең

Калса калыр безнең сөю
Татлы төш булып кына.
Үпкәләмим, диңгез дә бит
Бер дулап алгач тына.

Сөюдән кем туя икән
Яшәргә дәрман барда.
Сәфәр чыккан кораблар бер
Әйләнеп кайта ярга.

Сагынып утлы чәчәкнең
Ачылган минутларын,
Тезләнерсең мәхәббәткә,
Йотып сагыш утларын.

* * *

Күзләрем – күңел көзгесе,
Бак әле күзләремә.
Адашмый килеп керерсең
Наз тулы йөрәгемә.

Сабый хәлендә калсаң да,
Яратып туймам сине.
Соңгы сулышым алырмын
Кабатлап исемеңне.
Йөзләремә сагыш салды
Олыгаю чалымы.
Булдыралсаң, ачып укы
Яра тулы җанымны.

* * *

Барсына кул селтәп калыйммы яныңда,
Булыйммы терәгең, кадерлем.
Сөюем көч бирер яшәргә йөзгәчә,
Белербез тормышның кадерен.
Һәр сулыш алуың, һәр назың, һәр язың
Йөрәккә җыр булып язылыр.
Без бергә булганда, кыш килмәс шикелле,
Күңелдә мәңгелек яз булыр.
Сорармын Тәңредән, җирләрдән көткәнне
Бир, диеп, иркәмә гарештән.
Китермәм түземсез әҗәлне яныңа,
Булырмын саклаучы фәрештәң.

## Канаты көйгән күбәләк

Ник күрсәттең миңа бәхет илен,
Ник тирбәттең татлы хыялда?
Киттең. Калдым, яралы кош сыман,
Ишелергә әзер кыяда.

Белмәгәндә җирдә сөю барын
Яшәү башка иде, үзгәрәк.
Очып китте иңнән бәхет кошым,
Мин – канаты көйгән күбәләк.
Ник яраттым, нигә яраттырдың,
Нигә салдың газап утына?
Күктә кояш балкып елмайса да,
Җылы керми хәзер йортыма.

Үз кояшың, үз йолдызың сүнсә,
Адаштыра язмыш юлларда.
Кайт яныма, кайтар бәхетемне,
Бирә күрмә чит-ят кулларга.

* * *

Тормыш китабымның һәр битенә
Язмышымны үз кулларым язды.
Үзем иҗат иткән көйне көйләп
Сагышланды моңлы күңел сазы.

Үзем яздым, үзем укый бардым
Һәр җөмләсен, һәрбер яңа сүзен.
Кара төндә арып йомдым да мин
Таңны күрер өчен ачтым күзем.

Төсле бизәк белән бизи-бизи
Язам әле тормыш китабымны.
Ак хыяллар дәшә алга таба,
Сүндермә, җил, гомер учагымны.

*Ятим балаларны күңел канаты астына сыендырып үстергән хөрмәтле авылдашларым: Мәкмүнә апа Фәррахова, Шәмсекамал апа Мортазина, Энҗе апа Садыйкова һәм Фәрхеҗиан апа Мәннаповаларның олы йөрәге алдында баш иеп, тирән ихтирам йөзеннән*

## Мирас

*(Шигъри хикәят)*

Күҗәкәдә кояш та бит үзгә,
Ал нурыннан күзләр камаша.
Безнең урам күп балалы урам,
Алты-җиде бала йорт аша.

Авыл җанын тетрәндергән бер җәй
Уелып калды безнең хәтергә.
Аяз көнне яшен суккан каен
Авып төште салкын кабергә.

Балачакның якты, ал кояшын
Шушы көнне болыт каплады.
Киң урамның яшел чирәменнән,
Кайгы чәчеп, үлем атлады.

Чишмәләр дә агуыннан туктап
Тыңлагандыр ачы матәм көен.
Дөнья күтәрмәслек сагыш басты
Тракторчы Кәшбетдиннең өен.
*

Пар канаты Мөзәккирә апа
Алтынчысын тапкан көнендә
Кан югалтып җанын тәслим кыла
Бала туган изге мизгелдә.

Шул минутта бәхет тулы өйнең
Ишелдеме нигез кыясы?!
Яңа гына туган сабый калды,
Ул баланы кая куясы?!

Нәсел җебен ятлар кулга алса,
Ниләр басар җанның газабын.
Мирас булып калды хатынынннан,
Хәерле кыл, Аллаһ, азагын.

*

Мәрхүмәне гүргә иңдерүгә
Уйлаштылар, киңәштеләр бергә.
Алтын урталык та тиз табыла,
Әрсез кайгы үткән чакта түргә.

Бондюг каласына илтә китте
Яшь баланы алып ятим ир.
И Ходаем, сакла нарасыйны,
Бирә күрмә аңа берүк чир.

Яше тулгач килеп алырбыз, дип
Урнаштырып кайтты баланы.
Ятимнәрне сыендырыр җанны
Хәзер каян эзләп табасы?!

Йортка кайтса, тәрәзәләр моңлы,
Ихатада кайгы эзләре.
Кайсы якка гына карамасын,
Сагыш тулы бала күзләре.

Балаларын җыеп киңәште дә
Өйләнергә карар кылды ул.
Хак Тәгаләм, үзеңә тапшырам, дип,
Күрше авылга иртән тотты юл.

Бер ялгыз җан яши икән анда,
Бәлки, колак салыр сүзенә.
Кошчыкларын сыендырыр канат,
Тугры хатын булыр үзенә.

Мәкмүнә дә ирнең күзләрендә
Күрде үзәк өзгеч үтенеч.
Кире какса, тынгы бирмәс төсле
Күңелендә туган үкенеч.

Хыялыннан күпме өмет иткән
Язмышына өлеш шушыдыр.
Ике йөрәк, әрнүләрен басып,
Бергә тибәр өчен кушылыр.

Бала назын татымаган көйгә
Ризалаша ана булырга,
Тибәрмичә читкә сабыйларны,
Гаиләне саклап торырга.

Ияләшү җиңел булмагандыр,
Ят иткәндер башта балалар.
Сабырлыкны ияр итеп тотсаң,
Якыная ерак аралар.

*

Бер ел узгач, Кәшбетдине кабат
Сәфәр чыкты Бондюг каласына.
Мирас үскән. Аны күргәч, күктән
Диңгез суы тамды ярасына.

Авыл халкы хәйран калып уйлый
Исәннәрен, гүрдә ятканын.
Мәкмүнә апа көтә дулкынланып
Бала белән ире кайтканын.

Тәрәзәдән тәрәзәгә йөри,
Йөрәгендә утлы күмер көйри.
Авыл халкы, биш баласы күзли,
Һәр күңелдә ялкын-учак дөрли.

Яше тулган улын кочкан ата
Кайта иңләп авыл урамын.
Зәңгәр күкне алтын төскә манып,
Кояш сибә якты нурларын.

Түзми ана, биш баласы белән
Каршы чыга капка алдына.
Күз яшенә төреп, бәхет кошын –
Кечкенәсен ала кулына.

Таң калырлык батырлыкны күреп,
Җиңел сулап куя күрше-күлән.
Яшь ананың җылы карашыннан
Күтәрелеп китә яшел үлән.

*

Алты бала өйдә. Ире тырыш.
Бар тапканы уртак табында.
Алты үксез өчен Ана булды,
Үзенекен йөртә карында.

Җиденчегә гомер буе көткән,
Төшләренә кереп йөдәткән
Улы туды, Кәшбетдингә охшап,
Өзелеп төшкән бит ул йөрәктән.

Тапты бәхетен шушы гаиләдә,
Сабырлыгы өчен бүләктер.
Аның күкрәгендә типкән йөрәк –
Иң бәхетле, дәртле йөрәктер.

Бәхет диңгезендә йөзә Ана,
Куанычы сыймый эченә.
Таң каласың шундый аналарның
Бу дөньяда яшәү көченә.

*

Үскәндәге юклык, авыр хезмәт,
Тетрәнүләр эзсез узмаган.
...Ире авырып китте кинәт кенә,
Сула инде йөрәк сызлаудан.

Гомерләрне сатып алып булмый,
Качып булмый әҗәл тырнагыннан.
Соңгы йотым суны эчте ире

Назлап туймас яры кулларыннан.

*

Җиде бала. Мөлдерәмә күзләр
Сорау белән аңа төбәлгән.
Яшен суккан агач төсле берәү
Сынар иде сүзсез сүзләрдән.

Ялгызлыктан арып сусаганда
Тапкан иде бәхет чишмәсен.
Алты җанны ташлап, берсен алып,
Ни йөрәгең белән китәсең.

Сөеп-сөелеп яшәр өчен диеп
Аяк басып кергән бу өйдән
Китә алмый. Кала. Җаны белән
Балаларга күптән береккән.

Балалары бар да тигез булды,
Һәрберсен дә якын, үз күрде.
Соңлап тапкан олы бәхетеннән
Калган мирас яшәр көч бирде.

Балаларның күңеленә иман
Югалтулар аша кергәндер.
Әни, диеп өзелеп тора бар да,
Барысы да газиз, бердәнбер.

Үсеп буйга җиткәч, кызлар, уллар
Бер-бер артлы читкә таралды.
Бер дәшүе җитә, кайта алар
Якынайтып ике араны.
Барысы да башлы-күзле инде.
Бер-бер артлы туйлар уздылар.
Табын түре һәрчак ана өчен,
Рәхмәт әйтеп кулны суздылар.

Хәер-фатихасын биргән чакта,
Һәрберсенә бәхет теләде.
Шатлык килсә, сөенеп туялмады,
Борчу килсә, әрни йөрәге.

Ятимлекне тоймый үскәнгәдер
Өзелеп тора һәрбер баласы.
Сабырлык һәм түземлектән тора
Кайгы белән бәхет арасы.

*

Үги ана яфраклары бизи
Челтерәп аккан инеш буйларын.
Татлы моңга кушылып сүтәм һаман
Тере йомгак төсле уйларым.

Чит авылны, үги балаларны
Чын күңелдән якын, үз иткән

Бу ананың узган тормыш юлы
Кабатланмас моңлы җыр икән.

Тигез итеп бүлеп бар җылысын
Үстерде ул назлап җиде җанны.
Сүнмәс сөю хисе дәрман бирде
Каршыларга көлеп һәрбер таңны.
Мирас булып калган бар байлыкны
Таркатмыйча саклап яши Ана.
Мәхәббәткә тугры калу белән
Үз-үзенә аумас һәйкәл сала.

Күпләр өчен үрнәк, өлге язмыш
Төшендерә безгә яшәү ямен.
Зур йөрәкле Ана – якты бизәк,
Горурлыгы, даны Күҗәкәнең.

Учлап биргән бу бәхетнең башы
Тәүге улы – Мирас белән бәйле.
Юлдаш иткәч Ана гаделлекне,
Бар бала да булды игелекле.

Өч ир бала – өч бөркете аның,
Дүрт лачыны – уңган кызлары.
Ана горурлыгы булып ята
Җирдә сызган якты юллары.

Гомер биргән ана каберен барлап
Хаклый алар баккан Ана хакын.
Ана-бала мәхәббәте бизи
Гомер елгасының ике ярын.

## Хәтер яулыгы

*(Шигъри хикәят)*

Күңелемнең капкалары ачык
Җылынасы килгән кешегә.
Бүген тагын калтыранып, туңып
Килеп кердең төнлә төшемә.

Тиң иттең син үзеңә ялгызлыкны,
Туңадыр ла, сизәм, йөрәгең,
Минем белән бергә бәхет кошың
Ташлап очкач күңел тирәгең.

Артык горур идең. Таш кыядай
Басып калдың юллар чатында.
Уйламадың хәтта балаларның
Язмышлары, күңеле хакында.

Тәкәбберлек баскан йөрәгеңә
Еллар мулдан салган сагышны.
Бирмәгәндер тынгы, ээрлекләп
Гомерең буе, сөю тавышы.

Очрашканда башың аска иеп
Күрмәмешкә салынып үтсәң дә,
Хәтер яулыгыңа төреп мине

Йөртәсеңдер йөрәк кесәңдә.

Гаепләме ятлар? Юк, без икәү,
Таркалганга безнең гаилә.
Пар каеннар кочаклашып үсә,
Ялгыз таллар җилдә бөгелә.

Мине дә бит җилләр бөкте кайчак,
Сынмасам да, җиргә иелдем.
Әрнүләргә түзә алмаганда,
Сагыш булып җилгә түгелдем.

Парлыларга кызыгып карадым мин,
Ялгызларны жәлләп еладым.
Үз-үземне шелтә-камчы белән
Ничә еллар шулай кыйнадым.

Бар чагында кадерен белмибез дә
Югалтуга сагынып елыйбыз.
Көннәр түгел, айлар гына түгел,
Ялгыз үтә күпме елыбыз.

Сак белән Сок язмышларын биргән
Тәкъдирнеме тотып тиргәргә?
Күшеккән җан яшен түгә-түгә
Бәргәләнә кара төннәрдә.

Үтә гомер, ага салмак кына.
Ак бәс каплый чигә чәчләрен.
Күптән кипте синең гамьсезлектән
Үрсәләнеп түккән яшьләрем.

Син өйрәнгән кебек ялгызлыкка,
Мин дә күндем кырыс язмышка.
Исемеңне телгә алмыйм күптән,
Чынлап түгел, хәтта ялгыш та.

Ә шулай да бик еш рәхмәт укыйм
Бу дөньяда синең барлыкка.
Син яздырдың кыз һәм улны миңа
Язмыш биргән бүләк – ярлыкка.
Кулларымда бәхет кошы итеп
Оныгымны назлап уйнатам.
Киләчәгем онykларда, диеп,
Хыялымда үзем юатам.

Үкенерлек түгел узган гомер.
Кызым, улым – яшьлек дәвамым.
Үткәннәрне синең җаның аша
Киләчәккә яшьтән ялгадым.

Төшендем мин, чал чәчләрең нигә
Ак карларга охшый башлады.
Язмыш сые үзгәртә шул безне,
Имәсәк тә горур башларны.

Син кайчандыр минем өчен генә
Гармун алган идең кулыңа.
Мирас итеп калдырмадың аны

Нәсел җебе булган улыңа.

Улың ил сакларга киткән чакта
Көткән иде сине тилмереп.
Кайда йөрдең ул чак, ничек түздең,
Елаганда йөрәк илереп?

Улың өйләнгәндә никахына
Чакырсак та, горур, килмәдең.
Нәкъ синеке төсле зәңгәр күзле
Оныкк туууын да белмәдең.

Белмәү түгел, бу белергә генә
Теләмәүдән иде, аңладым.
Бездән түгел, горурлыгың өчен
Син каргышын алдың Алланың.

Шуңадыр ул ялгызлыкны кочып
Сагышланып үтә гомерең.
Тәү мәртәбә оныгыңны күргәч,
Йөрәгеңне учлап йөгердең.

Бала күзләрендә күргәнсеңдер
Бәхет төсен, бәхет очкынын.
Күз яшьләре юып ала алмас
Йөрәктәге сагыш юшкынын.

Аңлыймын мин бүген синең хәлне,
Битәрләмим сине шуңа да.
Тормыш – арба, гел-гел тәгәрәми,
Кайчакларда, беләм, шуа да.

Таеп егылмыйча басып калу
Килми бит ул һәркем хәленнән.
Оныгыңны ал син кулларыңа,
Татыр өчен бәхет тәменнән.

## Мин – Җир кызы

*Сугыш ветераны, кадерле әтием*
*Ситдыйков Мирзанур Ситдыйк улының*
*якты истәлегенә багышлыйм.*

Мин туганмын уттай эш өстендә,
Кыл кырыкка ярылыр вакытта.
Ул чагында ярдәм итәр өчен
Булмаган бит әле табиб та.

Кулга алган мине кендек әби,
Укый-укый изге догасын.
Талдан үргән бишеккә ул салган,
Килештереп бөтен йоласын.

Әнкәемнең йомшак кулы назлап,
Җырлый-җырлый мине тибрәткән.
Ана сөте белән кермәгәнен

Яши-яши тормыш өйрәткән.

Күңелемдә сүнмәс кояш яши,
Землянкага якты кергәндер.
Күзләрем дә җир төсендә минем –
Карашлары серле, тирәндер.

Әткәй белән Әнкәй өй салганнар,
Камыш белән ябып түбәсен.
Элеп куйган Әткәй өй түренә
Тимер чөйгә бишек сиртмәсен.

Такта сәке алты бала өчен
Тормыш сәхнәсенең үзедер.
Матча ярыгында тал чыбыгы,
Ул – вөҗданның ачык күзедер.

Сәке астында ике каз оясы,
Оя саен ишле бәбкәләр.
Ишегалды тулы кукраеп
Йөри төймә таккан күркәләр.

Кызыл киеп чыгып булмый өйдән,
Күркә куа безне кабарып.
Без качабыз, табан ялтыратып,
Чиләктәге суны аударып.

Чолан-чорма булды минем урын,
Китап укып илләр гизгәндә,
Тәүге тапкыр дәфтәр битләренә
Энҗе төсле сүзләр тезгәндә.

Тукай, Җәлил, Туфан шигырьләрен
Ихластан шунда ятладым.
Гомер буе чолан-чорма исен
Күңелемә төреп сакладым.

Үрмәкүчләр ятьмә үргән чорма
Ят күзләрдән мине яшерде.
Хыял белән йөзгән зәңгәр күктән
Әнкәй дәшеп җиргә төшерде:

«Тагын кайда эштән качып бүген
Багындың син китап битенә?
Укыр өчен китәр идең, – диеп, –
Булдыралсаң дөнья читенә».
Дөнья читен барып күралмадым,
Булмагандыр андый теләк тә.
Балачакның якты хатирәсе
Ядкарь булып калды йөрәктә.

Әткәебез завхоз булып эшли,
Колхоз өчен көчен аямый.
Көндез эштә, төнлә итек баса,
Арып кайтуына карамый.

Кулы алтын аның: балта тотса,
Ут уйната ике кулында.
Пычкы, ышкы биреп уйната ул

Үз һөнәрен олы улына.

Авылдашлар килсә ярдәм сорап,
Берсен дә ул бормый ирегә.
Өй дә сала, мал-туарын суя,
Кирәк булса, или тире дә.

Яшьтән ятим калып үскән Әнкәй
Талдай бөгелеп, сыгылып тормаган,
Кирәк чакта басуын да сөргән,
Атын җиккән, җирен тырмаган.

Кичке уен, сабантуйлар күрке,
Моң чишмәсе – Әнкәй тавышы.
Гомер буе җырлап җиңгән бит ул
Тормыш авырлыгын, сагышны.

Әткәй дә бит шуңа пары итеп,
Тиңе итеп аны сайлаган.
Яратышкан парлар кавышканнар,
Җил дә үтмәс булып арадан.
Әткәй булган хәлле гаиләдән,
Килен булып төшкәч бу өйгә:
– Хәерче! – дип әрләү, кимсетүләр
Кайнанадан Әнкәй ишетә.

Плугарьда йөргән вакытында
Авыр булган куйган хезмәте.
Ә әбекәй өйдә хуҗабикә,
Тик Әткәйгә булган хөрмәте.

– Ипи бары ирләр өчен, – диеп,
Ул Әткәйгә кискән телемен.
Әнкәй бала көтә... Тик шулай да
Эретә алмаган аның күңелен.

Каерып кискән ике телем икмәк
Кызыктырып тора табында.
Әткәй, әби күрмәгәндә генә,
Тыгып куя берсен куенга.

– Эшкә баргач ашарсың, – дип, Әткәй
Яшереп кенә суза Әнкәйгә.
Анага да тел тибрәтә алмый
Һәм ярыйсы килә Әнкәйгә.

Ярар өчен түгел, яратканга
Сузган бит ул аңа телемен.
Үз өйләре булса, бер җан булып,
Бергә бүләр иде керемен.

...Мин туасы елны, тыныша алмый,
Аерылып башка чыгалар.
Кеше землянкасы сыендыра,
Түзә парлар, алар чыдамнар.

Землянкада салкын, үзе юеш,
Эре-эре симез бакалар.
Төне буе йоклый алмый алар,

Киләчәкне уйлап яталар.

Әткәй, Әнкәй эшкә киткән чакта,
Ике апам калган янымда.
Өлкәненең ул чагында әле
Булган бары яше алтыда.

Мин бишектә, алар как өстәлдә
Утырганнар мине уйнатып.
Бакалардан куркып, елый-көлә,
Берсен-берсе назлап юатып.

Дүрт почмаклы өйдә алты бала,
Аралыкта сарык бәрәне.
Ашказанын йолкып, хуш ис бөркеп,
Мичтә пешә кайнар бәрәңге.

Шул чикмәнле бәрәңгенең тәме
Бар нәрсәдән безгә кадерле.
Бәрәңгедәй тәгәрәшеп үстек,
Уйнап-көлеп, белми җәберне.

Җиденчесе – төпчек туар елны
Әткәй кайтып керде елмаеп.
Ул сөйләгән чакта, барыбыз да
Киткән кебек булдык зураеп.

Безнең белән бергә киңәш тотып,
Сөйләшүгә нокта куелды.
Финский өй алып кайта Әткәй,
Тик сатарга кирәк сыерны.

– Сыерсыз да калсак нишләрбез? – дип,
Әнкәй генә елый, кайгыра.
Әткәй аңа: – Җитәр инде, Гөлсем,
Бар да булыр, – дия, – яхшыга.

Ярдәм була икән колхоздан да,
Эшләгәнне күрә беләләр.
Сыер сауган олы апага да
Ссудага акча бирәләр.

Ишегалды тулы такталардан,
Сүс, цемент һәм ташлы комнардан
Була микән әллә өй җиткереп?
Арынмый баш шушы уйлардан.

Сызымнарын сузып салды Әткәй,
Каләм, кәгазь алды кулына.
Мыек сыйпап, ул елмаеп ала,
Күзен кысып кыз йә улына.

Нигез салган чакта һәрберебез
Өлеш кертү өчен тырышты.
Беребез алып килсә ташлы комны,
Икенчебез суын ташышты.

Цемент, комны, суны бутый-бутый,
Әткәй измә ясый тырышып.

Куанычлар эчкә сыймый безнең,
Армыйбыз һич аңа булышып.

Ә аннары өемдәге такта
Стеналар булып үрләде.
Безнең генә түгел, Әткәйнең дә
Күзләрендә учак дөрләде.

Шифер түбә менеп кунаклады
Әткәй җыйган өйнең өстенә.
Алып батыр төсле икән Әткәй,
Булса да бик чандыр, кечкенә.

Өч бүлмәле иркен өйдә кухня,
Ашау, йокы һәм ял бүлмәсе.
Юына торган кече ягы да бар,
Суны гына тышка түгәсе.

Май аенда туган көне үткәч,
Әнкәй китте бала табарга.
Әткәй уйда: нарасыйны кайсы
Өйгә белми алып кайтырга.

Яңа өйгә ягып булмый әле,
Искесенә тартмый күңеле.
Безне җыеп әткәй киңәште дә
Әйтте җөпләп шундый фикерне:

– Яңа туган сабый башлап керсен,
Бәхет теләп безнең тормышка.
Күченәбез өйне җыештырып,
Әниегез кайта торышка.

Яңа өйгә күчә безнең белән
Талдан үргән бала бишеге.
Бисмилласын укып, төпчек улга
Әткәй ачты өйнең ишеген.

Үз куллары белән салган йортның
Сыйпап үтте хәтта тупсасын.
Шушы өйдә, Ходай, бәхет булсын,
Бала тавышлары тынмасын.

Безнең шатлык өйгә генә сыймый,
Шундый биек, иркен булса да.
Ә иске өй шушы көннән башлап
Әйләнде бер кара мунчага.

Самоварда Әткәй өчен генә
Пешә һәр көн ике йомырка.
Өстәл тирәсендә, төкерек йотып,
Җиде пар күз көтеп утыра.

Әткәй алып йомырканы әрчи,
Бармагында йөри безнең күз.
Чебен очса, ул да ишетелә,
Тик авыздан чыкмый сыңар сүз.

Әткәй безгә күтәрелеп карый,

Үткен пычак ала кулына.
Тигез итеп кискән җиде өлеш
Күчә кызлар, уллар кулына.

Тавык суйсак, Әнкәй бүлеп бирә
Тигез итеп безгә калҗаны.
Бүлә торгач, канат очларыннан
Башка берни үзенә калмады.

Авыздагы тәмле ит кисәге
Чәйнәлеп тә әле бетмәгән,
Кулдагысын Әнкәемә сузам,
Мөлдерәмә күзгә текәлгән.

– Ит яратмыйм, кызым, үзең аша,
Миңа җитә канат очы да, –
Назлы караш сыйпап ала җанны,
Тамактагы төер ачы ла.

Хәерле юл теләп без калабыз,
Әткәй, Әнкәй эшкә киткәндә.
Төш вакытын көтеп җырын суза
Җиз самовар имән өстәлдә.

Ә төштән соң «уфалла»ны тартып,
Чәтертәнгә менеп китәбез.
Арба тәгәрмәче җырын тыңлап,
Әрәмәгә барып җитәбез.

Печән чүмәләсен җайлап кына
Сәнәк белән төйи малайлар.
Тасма кебек такыр юлга карап,
Кайтыр юлга борыла арбалар.

Берсе алдан тарта, берсе арттан
Сәнәк белән этә тырышып.
Юл буенда көтә тигәнәкләр
Кайтыр өчен тезгә сырышып.

Арсалар да, кайтып җиткән чакта,
Горур гына тотып башларын,
Кызулыйлар атлар адымнарын,
Җыергалап кара кашларын.

Сынатасы килми, кеше күзе
Күрмәсен дип безнең арганны,
Җиңеләйтеп тарткан була алар
Чүмәләле авыр арбаны.

Капкадан ук каршы ала назлап
Яңа пешкән икмәк исләре.
Юл тузаны баскан малайларның
Балкып китә арган йөзләре.

– И улларым, – диеп, Әнкәй, сөеп,
Аркаларын каккан чагында,
Кояш чыккан төсле балкып китә
Тугыз җанлы тулы табын да.

«Сибелә чәчем» җырын җырлый Әнкәй,
Сибелгәндер җилләр искәндә.
Үсеп җиткәч, без дә җиде бөртек
Сибелештек төрле җирләргә.

Барыбыз да тапты бу тормышта
Үз урынын, корды оясын.
Үскәндә ни күрсәң, очканда – шул,
Үз җилкәңдә аны тоясың.

Арада бар авыл эшчәннәре,
Штукатур-маляр, төзүче.
Күпне күргән Әфган солдаты да,
Себер киңлекләрен гизүче.

Җиденчебез – төпчек энебезгә
Иң җаваплы, изге вазифа:
Төп нигезне таркатмыйча яши,
Кирәк чакта һәрчак кул суза.

Әткәй инде гүр иясе күптән,
Дөнья белән иртә хушлашты.
Йөрәк түрендәге урыны зур,
Ныклы нигездәге өй чаклы.

Туган йортның ихатасы булсын,
Йортка каккан һәрбер кадагы
Барчабызның күңелендә яши,
Әткәбезнең булып дәвамы.

Җиде җанга гомер биргән Әнкәй,
Җигелеп тартты тормыш арбасын.
Сыгылмый һәм сынмый яшәгәнгә,
Дөньялыкта күрә савабын.

Безнең өчен яшәү өлгесе ул,
Һәрберебез өчен кадерле.
Әткәй биреп китте бәхиллеген,
Гомере дә шуңа хәерле.

Балаларың бик бәхетле, Әнкәй,
Бәхет өчен сиңа бурычлы.
Ныклы рухың, сынмас сабырлыгың
Көнләштерер иде корычны.

Бер җаныңа җиде шатлык сыеп,
Җиде тапкыр янып-көйгәндер.
Маңгай-битләреңдә сызылып киткән
Буразналар шуңа тирәндер.

Синең куллар назы белән күчкән
Йөрәкләргә кояш җылысы.
Җидебездән җиде шатлык булып
Бәхетләрнең килсен олысы.

Җир куенында туган бала бит мин,
Җир куенына кабат китәсе.
Аңа кадәр әле, алга карап,
Күпме юллар бардыр үтәсе.

Олы юлның башы авылымның
Капкасына барып тоташкан.
Тормыш юлы артык сикәлтәле,
Килмидер ул шатлык тоташтан.

Хәер, әгәр гел шатлыктан торса,
Булыр идеме соң кадере?
Авырлыкны җиңеп атлаганга,
Бу дөньяда яшәү кадерле.

Җырлар язам, Ходай тарафыннан
Миңа тигән бәхет-өлешем.
Тик сүнмәсен йөрәктәге учак,
Кирәк түгел алтын-көмешең.

Җир куенында туган Җир кызы мин,
Кендек белән җиргә береккән.
Тамыр җәйсен диеп күңелләрдә,
Әйтер сүзне җырга күчерәм.

## Бала елый

Яшьлек гүзәл... Ә шул гүзәллекне
Саклый алабызмы мәңгегә:
Кем югала юлда очрап упкын,
Кем сыгылмый биек үр менә...

...Алсу йөзле, кара бөдрә чәчле,
Зифа буйлы гүзәл сылуга
Әзерләнгән каһәрләнгән сөю –
Шулдыр сәбәп канат сынуга.

Гармун тотып каршы атлый егет.
Кыйгач кашлы, үткен карашлы.
Шулмы әллә гомерлеккә тиңе,
Шулмы аның пары, җанашы?!

Кайдан тойсын уналтысы тулган
Бу гөнаһсыз корган тозакны?
Яшь күңелгә ургып сөю керде,
Ачкычларсыз ачып йозакны.

Сөйде шашып, дөньясын да онтып,
Тик гармунчы булды уенда.
Ә «насыйбы» күптән башка белән
Биегән шул кызыл туенда.

...Яшьлек җүләр, гашыйк күзе сукыр,
Соң ачыла күңел күзләре.
Кыз алданды, әче ачынуның
Яра булып калды эзләре.

Китте яры. Ул аныкы түгел:
Гаиләсе, нәни улы бар.

Ә яшь Сылу аның өчен бары
Гади курчак – уйнап сөйгән яр.

Япь-яшь кызның башын әйләндереп,
Намусын да буяп карага,
Хушлашмый да беркөн китеп барды
Гаиләсе торган калага.

Сылу калды тапталган гөл сыман,
Саргаеп һәм көеп, сулыгып...
Яшәр өчен газап кочагында,
Күз яшенә ялгыз кол булып.

Ярасыннан саркый йөрәк каны,
Карынында тибә баласы.
Кеше күзләренә ничек багар,
Бәхилләрме газиз анасы?

Канатлары сынды очар кошның,
Барыр юлын томан каплады.
Адашкан җан тормыш тозакларын
Ачар өчен ачкыч тапмады.

Нинди өмет аны алдап йөртте
Җан иңгәнче шушы сабыйга?
Ана булу – олы бәхет, диләр,
Ник соң Сылу тоташ кайгыда?

Кача-поса ят күзләрдән кызый
Бала туар көнне көткәндә
Аңлап алды: теләсә дә ничек,
Юллар ябык икән үткәнгә.

Вөҗдан газапларын баса алмый,
Күз яшьләре битен юса да,
Рәнҗетелгән сөю җәза булып
Көтә аны алда – тупсада.

Төнлә белән, тулгак тоткан чакта,
Әрнүләрдән кысып тешләрен,
Ышык эзли подвал ишегеннән,
Бәрә-суга ташка тезләрен.

Аңы томаланды ямьсез уйдан.
(Ахры инде, шашты акылдан...)
Башына килми, ул адымга барса,
Нәрсә көтә аны ахырдан?

Алда чарасызлык, алдау чире,
Җәмгыятьнең черек нигезе...
Йотар төсле бала белән бергә
Сазлыкка тиң тормыш диңгезе...

Бала белән бәйләп торган кендек
Җебен чәйнәп өзгән анага
Үз каны да акыл иңдермәде –
Нәни бала салды хафага.

Туды бала. Күңел тулы сагыш,

Сайлап тапкан ачы язмышы...
...Соңгы көнгә кадәр ияръчәк
Арттан калмый, кылса ялгышны.

Буталды бар дөнья, җир убылды,
Белешмәде кеше үз-үзен:
Җанын Иблис суырып алган ана
Бәреп ватты вөҗдан көзгесен.

Чүп савытын тәүге бишек итте
Яңа туган сабый балага.
Төн карасын томан алыштырды,
Пәрдә корып ике арага.

Бала елый... Үрсәләнеп елый,
Эзли имчәк – ана күкрәген.
Шушы аваз җиһан җанын тырный
Һәм сызлата җирнең йөрәген.

Этләр урап алды чүп савытын, –
Юаталмый алар нәнине,
Өзгәләргә әзер булсалар да
Чүпкә бала салган «әни»не.

Тиле ана чәчен җилләр йолкый,
Аңлатырга теләп хатасын:
Җаны барлар ятка ташлап качмый
Җанны ярып туган баласын!

Кача ана, әллә баласыннан,
Әллә кача үзе-үзеннән.
Белми әле – алда көткән җәза
Авыррак сырхау-үлемнән.

Колагында яңгыраган тавыш –
Үзәк өзгеч бала елавы...
Гасырга тиң озын чирү-газап –
Алда яшәячәк еллары.

Бала елый... Җиһан үкси... Үкси...
Әй адашты сөю, адашты.
Дөнья күзе бага галәм аша
Акылыннан язган карашны.

Шашынган күз чүп савытларыннан
Актарынып эзли баласын.
Җил сызгырып арттан куа килә,
Тирәнәйтеп йөрәк ярасын.

Бала елый... аның саен ана
Кызулата атлар адымын.
Бер савыттан бер савытка чаба,
Табар төсле гүя сабыен.

Таныгандай итеп, теш ыржайтып,
Этләр үтә өреп яныннан.
...Нигә Аллаһ аны җирдә йөртә,
Аермаган нигә җаныннан?!

Бала елый... Туфан купканда да
Басылмастыр елау тавышы.
Үткән еллар, узган юллар аша
Телә җанны сабый каргышы.

* * *

Йөрәгем сизсә дә ялганны,
Җылыга сусаган җаныма
Наз белән яралган һәрбер сүз
Бал белән май булып ягыла.

* * *

Үз хаклыгың исбатлавы авыр,
Танытырга авыр дөньяга...
...Чишмә суы сафлык өстәр өчен
Суын коя алкын елгага.

* * *

Әйләнә дә тулгана җир
Кулдагы орчык сыман.
Мизгелдәй кыска гомергә
Нинди язмышлар сыйган.

* * *

Бикләнмәдем. Яшәдем мин
Шыр ачык күңел белән.
Офыкка барган юлыма
Көз җәя алтын келәм.

* * *

Аяк чалып ексалар да,
Күтәрелер көч табып,
Яшәгән чаклар булган бит
Учактай дөрләп янып.

* * *

Таңсылуның садәлеген күреп,
Кояшның да тетри керфекләре.
Ал нурларга үрелеп, күккә аша
Үләндәге энҗе бөртекләре.

* * *

Бишектән үк канга сеңгән
Сандугач тавышлары.
Тоташ бер моңга әйләнә
Гомерем агышлары.

* * *

Ике йөрәк кушылганда,
Дөрләп кабына учак.
Дәртле хисләр ташкынына
Әйләнә шулчак кочак.

* * *

Күмелгән хисләрем туфракка
Чыгармы гөл булып бирәр яз?
Ышанам: яңгырар сөюдән
Яралган сагышлы кайтаваз.

* * *

Уттай кочагыңа алдың,
Дары бөртеге идем.
Кабындым, яндым, яндырдым, –
Гаепле бары үзең.

* * *

Аңламадың минем хисләремне,
Нинди гамьнәр сине алга дәште?
Йөргән юлларыңда адашмаска
Учымдагы йөрәк нурын чәчте.

* * *

Теткәләде, кызганмады язмыш.
Табышмы син, әллә ялгышмы?!
Синең йөрәк челпәрәмә килде,
Минекендә – сөю каргышы.

* * *

Гасырлардан җыйган моңны саклый урман,
Сыкрап ага җирнең каны – кара алтын.
Тап төшерми исеменә Адаемның,
Яшимен мин хаклап халкым, милләт хакын.

* * *

Киңәш-табыш итеп яшьләр дәшсә,
Күңелләргә тула олы шатлык.
Картлык килми өлкән яшькә җиткәч,
Кирәклегең беткәч килә картлык.
* * *

Тән ярасын вакыт дәвалады,
Җан ярасы сыкрый, әрни һаман.
Күңел түрендәге манарада
Үткән гомер әйтеп тора азан.

* * *

Энҗе бөртекләре төптә ята,
Ялтырамый су өстенә калкып.
Тышың түгел, эчең ялтырасын,
Күңел яктылыгы – нурдан балкып.

* * *

Ратканын сыный бит ул
Хак Тәгалә дөньяда.

Үз-үземне таптым җырда,
Горурланам шуңа да.

* * *

Көзнең күзе юеш, кибеп тормый,
Тамчы-тамчы яше коела.
Яңгыр яуган төсле яфрак ява,
Җылы эзләп, җиргә сыена.

## Эчтәлек


Шигырь күзләрендә — Сөю һәм Наз. *Р.Гаташ* .........

**I бүлек**

«Мин дә каен, минем дә бит...» ..................
Ак чишмәле илем ...........................
«Очам күккә синең кочагыңда...» .................
«Минем дөньям чиксез галәм төсле...» ............
«Туганда ук маңгай күзен биргән...» ..............
«Үз-үземне табар өчен күпме...» .................
«Ил ялгышын, ир язмышын уйлап...» ..............
«Чәчемә көмеш кунса да...» ....................
Күңел ..................................
Мин яшим ...............................
«Туган авылым, һәр ел саен сиңа...» ...............
«Кайткан саен, туган авылкаем...» ................
Куҗәкә .................................
«Җитәкләшеп уздык бүген...» ...................
«Җәй куенында миләш кызы...» ..................
«Кумәкләшеп нигез салган йортның...» .............
Илерү ..................................
«Халкымның йөрәге гел тоташ кан-яра...» ...........
«Барыбыз да язмыш колы...» ...................
«Төймәдән дөя ясыйлар...» ....................
«Кызыктырып яна, дөрли учак...» ................
Чыныгу .................................
«Кашкарыйлар сулып ята...» ....................
«Гомер – йомгак. Сүтә-сүтә җебен...» .............
«Күпме яраланган күңел...» ....................
«Минем дә бар җирдә үз урыным...» ..............
«Җир түгәрәк, дөнья иксез-чиксез...» ..............
Уй ....................................
«Бар дөньяга хуҗа сыман йөри...» ................
Әле ярый ...............................
«Сискәндереп син бер әйткән идең...» .............
«Мин дә күрдем сине, Шагыйрь...» ................
«Елмайса да кояш нуры...» .....................
«Наз тулы яз килде дөньяга...» ..................
Яшел шигырь .............................
Яз җыры ................................
Караш .................................
«Күңел кылын өзгәләмә...» .....................
Ләззәт учагында ...........................
«Давыл тулы йөрәгемә...» .....................
«Сагынасыңмы диеп сорыйсың син...» .............
«Көпә-көндез, йокламаган килеш...» ...............
Яшен ..................................
Тимә ..................................
Керфек җиле .............................
«Күңелемдә боз кузгалды...» ....................
«Алларымда пар алмалар...» ....................
«Киләм диеп хәбәр бирсә иркәм...» ...............
Кар яуганда ..............................
Җанда сөю ялкыны .........................
«Кемгә килә сөю иртә язда...» ...................
Онытылсаң оныт ...........................

«Мин киткәндә күзләр елап калыр...» ..............
Йолдыз нуры .............................
Түзәрсеңме? ..............................
«Көчем җитми үзгәртергә...» ..................
«Йомшак куллар чәчтән сыйпый...» ...............
«Кылдан нечкә, нәфис хисләр бәйли...» .............
«Төн кочагы икебезгә уртак...» ..................
«Соңгы кат назланып кочакта...» .................
Парлы бию ...............................
«Баһадирдай ирнең кочагында...» ................
«Грозныйда канлы сугыш бара...» ................
«Син киттең дә юкка чыктың, улым...» .............
«Сагынганда тулган айга карыйм...» ..............
Күнләшү ................................
«Җан сусауга түзми, кулларына...» ................
«Чык та төшеп өлгермәгән әле...» .................
«Мәңгелеккә атлар тарихың бар...» ................
Сиңа кайткач .............................
«Җирем, күгем, газиз илем! ....................
Тургай җыры .............................
Соңлап килгән мәхәббәт ......................
Уяну ..................................
«Язмыштан юралган бәхетне...» .................
«Буш үтмәгән миңа язган гомер...» ...............
«Гасырларга җитәр җырлар язган...» ...............
«Түгәрәк диләр дөньяны...» ...................
«Җәбергә, золымга юлыктым...» .................
«Бала елый туу мизгелендә...» ...................
«Әллә заман, әллә без гаепле...» ..................
«Тау артыннан биек тауга мендең...» ..............
Юлчы ..................................
Йөрәгемә яфрак сыена .......................
Песнәк .................................
Кыш көткәндә .............................
«Бар табигать кышны көтә...» ...................
«Ала карга төсле туң җир...» ....................
Җавап эзлим ..............................
Ятим бакча ..............................
Уйлану .................................
Туңган чия ...............................
Сиреньнәр ...............................
Балан ..................................
Күзләр килә ..............................
Түз, йөрәгем! .............................
«Алиһәдәй чибәр, садә кызым...» ................
«Нәрсә кала миннән, китә калсам...» ...............
«Дөреслекнең йөзе нинди була?..» ................
«Үлчәп булмый микъдарларда...» ................
«Чиксез галәм киңлегендә...» ...................
Адашкан җаннар ...........................
«Мин дә Тукай, Җәлилләрне биргән...» .............
Сандугач ...............................
«Күз сирпү дә җитә, кай күңелнең...» ..............
Минем күңел .............................
Хәтер йомгагы ............................
Шагыйрь җаны ............................
Эз ....................................
«Ничәмә кат сынаса да язмыш...» .................
«Бурычларым бик күп, түли алмыйм...» .............
«Күп вакытта ашыгабыз бугай...» .................
«Чыр-чу килеп бала-чага уйный...» ................
«Кышлау карны җилләр ялап ала...» ...............
«Яз сулышын сизә күңел...» ....................
«Ишетәсезме, кошлар шашып сайрый...» ............
«Язгы җилләр каен кызын үбә...» .................
«Бөреләр, кысып күзләрен...» ...................
Язгы җыр ................................
Мизгел .................................
Дәртле тамчы .............................
«Кызган җиргә бии-бии...» ....................
Болыт мендәре ............................
Күзге аһәң ...............................
«Күзләрнең дә була аяз күне...» ..................

«Утлы чәчкә булып кышта...» ....................
Каен зары ................................
Күз ...................................
«Җаным яна. Күзләремнән...» ....................
Соң ...................................
Өзелгән җыр ..............................
Учак ...................................
«Сакламадык. Сөю хакын хакламадык...» ............
Пар алма ................................
Яратасым килә ............................
«Назлардан югалттым башымны...» ...............
Бәхет төне ...............................
Сөю алмалары ............................
«Мин төшемдә Казан ханлыгына...» ...............
Тылсымлы көй ............................
Җанда кабынган учак .........................
Сөю хисе ................................
Болыт ..................................
Яныйк әле ...............................
Утлы җимеш ..............................
«Утта янган чаклар бик күп булды...» .............
Тезләнерсең ..............................
«Күзләрем – күңел көзгесе...» ....................
«Барсына кул селтәп калыйммы яныңда...» ...........
Канаты көйгән күбәләк ........................
«Тормыш китабымның һәр битенә...» ..............

**II бүлек**

Мирас *(Шигъри хикәят)* .......................
Хәтер яулыгы *(Шигъри хикәят)* .................
Мин – Җир кызы ...........................
Бала елый ................................

Дүртьюллыклар ............................

Литературно-художественное издание

**Ситдикова** Альфия
(**Хазиахметова** Альфия Мирзануровна)

## Огненная ягодка

Казань. Татарское книжное издательство. 2011

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Ситдыйкова** Әлфия
(**Хаҗиәхмәтова** Әлфия Мирзанур кызы)

## Утлы җимеш

Мөхәррире *Р.В.Сабирҗанов*
Рәссамы *Р.Ш.Галиуллина*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы
*Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректоры *Г.Г.Зиннәтуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 28.01.2011.
Форматы 70×90 $^1/_{32}$. Шартлы басма табагы 5,26.
Тиражы 1500 д. Заказ Р-82.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Татмедиа» ААҖ филиалы
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.

420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.